# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ
3/ 2022

*Түбәтәй сүзе «түбә», ягъни баш түбәсенә киелүче әйбер мәгънәсен аңлата. Урта гасырлар сугышчысының очлым (шлем) астыннан киелгән баш киеменнән килеп чыккан дигән фикер дә бар. Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында сугышчыларның металл шлем астыннан шундый баш киеме киюен кайбер тарихчылар билгеләп үтә.*







# Татарстан Республикасы көнендә XXXVII «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты бәйрәме узды



Бирегә Татарстан һәм Россия төбәкләреннән 1000нән артык гармунчы җыелды. Г. Камал театры алдындагы сәхнәдә башланып киткән бәйрәмдә «Түгәрәк уен» Бөтенроссия фольклор фестивале лауреатлары һәм татар эстрадасы артистлары чыгыш ясады. Бәйрәм тантанада катнашучылар һәм гармунчылар парады белән дәвам итте. Аны Татарстан Республикасының атказанган артисты Фирдүс Тямаев җитәкләде. «Бүген зур бәйрәм! Без гармуннар уйнап, Бауман буйлап, Кремльгә килдек. Киләчәктә дә безнең милли бәйрәмнәр гөрләп торсын. Дөньяның нинди генә төбәгендә торсагыз да, кем булуыгызга карамастан, кулыгызны күкрәгегезгә куеп, горурланып, «мин татар» дип яшәгез», – диде ул.

«Уйнагыз гармуннар» фестивале республикабызда 1985 елдан бирле уздырыла. Әлеге чараны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге бергәләп үткәрә.



## ЭЧТӘЛЕК

### ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ




4 **Ага Базар яңарды**

7 **Ирада Әюпова: «Милли кием телен лингвистик телгә караганда тизрәк югалтуыбыз мөмкин»**


10 **«Түгәрәк уен» фестивале традицион очрашу урынына әверелде»**


### ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ




14 Ф. Мәрданова
**Түбәтәй**


### ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ




18 И. Закирова
**Илсөяр Закирова: «Безнең якта соңгы Чабыр бәйрәме 1940 елда узган»**

24 А. Әскәрова
**Килен төшә бүген авылга...**



Түгәрәк уен

№ 3 (45) / 2022


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 13.09.2022
Чыгу көне: 23.09.2022
Заказ: 065831 Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта: Түбәтәй.**
**Авторы Л.Фәсхетдинова.**



© «Түгәрәк уен», 2022

СӘНГАТЬ



30 Л. Шкляева
**Халыкның сәнгати ачышы**

БЕЗГӘ ЯЗАЛАР

35 Л. Сәнгатуллина
**Авылымның ямьле кичләре**

ӘДӘБИ МИРАС





38 Л. Шарова
**«Карурман: язылмаган дастан» пьесасы һәм спектакле мисалында милли эпосның заманча чагылышы**

ЭКСПЕДИЦИЯ



42 Л. Мөхәммәтҗанова
**Мөслимлеләрдән – халкыбыз хәзинәсенә рухи мирас**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...



48 **Чабаксар. Фольклориада. «Әллүки»**

51 **Уңыш** *(Жыр)*

52 Р. Шәйдуллина
**«Чәк-чәк» бәйрәме**

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ



56 **Әти-әниләр колагына**

ӨЙ КҮРКЕ – АШ



58 **Талкыш кәләвә: Борһан бабай бүләге**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

62 **Шахворд**



# Ага Базар яңарды

**Быелның 22-23 июль көннәрендә Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы биләмәләрендә ике көн дәвамында «Ага Базар» II Халыкара этномәдәни фестивале гөрләде.**

Фестивальгә исем итеп алынган «Ага Базар» атамасы – Болгар дәүләтендәге борынгы базар исеме. «Атаклы Болгар каласы, шау-шулы Ага Базар. Иделдә ерак иллләрдән килгән сәүдә кораблары, яр буенда һөнәрчеләр бистәсе, остаханәләр, йөзләгән кибетләр, алачыклар», – дип сурәтли аны галимнәр.

Ә яңа «Ага Базар» – үз мәйданчыкларында иҗат коллективлары чыгышларын, һөнәрчеләрне, белем бирү семинарларын, интерактив уеннарны һәм киноны да берләштергән уникаль проект.

«Ага Базар» фестивале нибары икенче ел гына үткәрелә. Аны Татарстан халкының һәм туристларның ял планына кертү өчен вакыт кирәк. Әмма фестивальнең киңкырлы программасы төрле аудиторияне кызыктыра алырлык. Әйтик, фестивальнең быелгы программасына «Иске Казан түгәрәк уены» фестивале



















чыгышлары, «Derrey Folk Sound» этномузыка лабораториясе, «Uen fest» фестивале дәресләре һәм башкалар кертелгән иде. Кичкә калган кунакларга «Юха» фильмы да күрсәтелде.

Ике көн дәвамында ярминкә эшләде. 200дән артык һөнәрче үз товарын тәкъдим итте һәм осталык дәресләре уздырды. Теләге булганнар үз куллары белән сувенир ясады.

«Чирәм» программасы дару үләннәре белән таныштырды, халык медицинасы осталары дару үләннәрен әзерләү һәм куллану серләрен ачты. Чәй церемониясе «Ага Базар»ның быелгы яңалыгы: төрле баллардан авыз итеп, үләнле чәй эчәргә мөмкин иде.

Кунаклар киләсе елга кабат килү нияте белән таралышкан икән, димәк, фестивальнең киләчәге бар.






# Ирада Әюпова: «Милли кием телен лингвистик телгә караганда тизрәк югалтуыбыз мөмкин»

**«Тормыш стиле – мәдәни код» II халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать этно-fashion фестивале Казанның туристлар белән кайнап торган мәлендә үтә. Быел ул 2-14 август көннәренә туры килде.**

Фестиваль киң колачлы – биредә һәр кеше үзе теләгәнне таба ала. Фестиваль эченә эшлекле дискуссияләр дә, фәнни-гамәли конференция дә, этник музыкаль мирас фестивале дә, этнодизайнерларның Fashion-кием күрсәтүләре дә, күргәзмәләр дә, мастер-класслар да, этномаркет та сыйган иде. Боларга Казан халкы һәм кунаклары түләүсез катнаша алды.

Әйтик, фестивальнең төп чараларының берсе булган эшлекле программада сүз креатив индустрияләр үсеше өчен шартлар турында барды. Катнашучылар – Россия товарына













ихтыяҗ арту мөмкинлеген дә фаразлады. Дискуссиядә Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова, Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева, Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы директоры Ольга Гыйльметдинова һәм башкалар катнашты.

«Без бу форумны икенче тапкыр уздырабыз. Ул мәдәният турында гына түгел, безнең мирасыбыз һәм тарихыбыз турында. Без бу форумны формалаштырганда тормыш стиле турында уйландык. Ничек киенәбез, ашарга нәрсә әзерлибез, балаларны ничек тәрбиялибез, нинди бишек җыры җырлыйбыз, тирәлегебезне ничек көйлибез – болар барысы да мәдәни код. Милли кием дә – тел, символлар. Без аны лингвистик телгә караганда да тизрәк югалтабыз. Символ телен саклау катлаулырак, югыйсә алар милли үзтәңгәллекне саклау өчен ныклы нигез булып тора», – диде эшлекле форумда ясаган чыгышында Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова.

Быел фестиваль Россиянең 28 регионыннан – Башкортстан, Бурятия, Чувашия, Саха (Якутия), Удмуртия, Мордовия









Республикалары, Ханты-Манси округы, Мәскәү, Красноярск, Сочи, Иркутск шәһәрләре, Пенза, Түбән Новгород өлкәләре, Ставрополь крае, шулай ук алты илдән – Кыргызстан, Төрекмәнстан, Казахстан, Таҗикстан, Азәрбәйҗан, Үзбәкстаннан 35 дизайнерны җыйган иде. Элара Шәйхи, Солтан Салиев, Руслан Габов, Юля Әхмәтҗанова, Илдар Гатауллин кебек билгеле Казан дизайнерлары да, «Милли Хәситә», «Йон Йон» брендлары да, А.С. Пушкин исемендәге мәдәният һәм Рус фольклоры үзәкләре дә этноколлекцияләрен тәкъдим итте. Мөгаен, тамашачының иң күп алкышларын җыйган коллекция Үзбәкстан бренды Lali булгандыр.

Фестивальнең хедлайнеры – worldmusic һәм ethno жанрларында иҗат итүче дөньякүләм танылган җырчы GURUDE иде. GURUDE – Россия Президенты премиясе лауреаты, Халыкара ТЮРКСОЙ оешмасы медале иясе, хакас җырчысы Руслан Ивакинның сәхнә псевдонимы. Бу аның Казанда беренче чыгышы иде.

Фестиваль дәвамында Камал театры алдындагы мәйданда ярминкә гөрләде. Россиянең төрле өлкәләреннән килгән һөнәрчеләр һәм билгеле брендларның вәкилләре үз товарын тәкъдим итте. Ярминкәдән Казан халкы һәм кунаклар өзелмәде.





# «Түгәрәк уен» фестивале традицион очрашу урынына әверелде»




**Август аенда башкалабызның «Чулпан» мәдәният үзәгендә XIV «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале-конкурсы узды.**

Концерт мастер-класслар һәм интерактив программа белән үрелеп барды. Әлеге фестивальдә республикабызның 23 районыннан 52 иҗат коллективы һәм башкаручы, Киров, Мордовия, Башкортстан, Удмуртия, Санкт-Петербург, Ульяновск, Чиләбе, Омск кебек Россия төбәкләреннән 10 коллектив катнашты.

Быелгы фестивальдә «Авыл көйләре» композициясен традицион көнкүреш коралларында оста уйнап, тамашачыларны һәм жюри әгъзаларын шаккатырган Чиләбенең Нязепетровск районы Араслан авылыннан килгән «Ләйсән» халык фольклор ансамбле (җитәкчесе Роза Мөхәррәмова) Гран-при иясе булды.



**«Ләйсән» халык фольклор ансамбле**

– «Түгәрәк уен» фестивале илебезнең төрле почмакларыннан килгән уникаль башкаручыларның традицион очрашу урынына әверелде. Елдан-ел күбрәк коллективлар кызыклы музыкаль репертуар алып килә, – ди Мәдәни ресурслар үзәге директоры Алсу Мифтахова.




- **Әлеге фестиваль Россиядә татар фольклорын тәкъдим итүче бердәнбер фестиваль.**
- **Тәүге тапкыр ул 2010 елда Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткы районында үтте.**







- **Фестиваль татарларның төрле этник төркемнәрен берләштерә. Татар халкын мәдәни мирасы белән таныштыра.**
- **Әлеге чараны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге бергәләп үткәрә.**



Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Түбәтәй

*Филүзә МӘРДАНОВА,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Ш. Мәрҗани исемендәге тарих*
*институтының кече фәнни хезмәткәре*

**Түбәтәй сүзе «түбә», ягъни баш түбәсенә киелүче әйбер мәгънәсен аңлата[1]. Урта гасырлар сугышчысының очлым (шлем) астыннан киелгән баш киеменнән килеп чыккан дигән фикер дә бар. Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорында сугышчыларның металл шлем астыннан шундый баш киеме киюен кайбер тарихчылар билгеләп үтә[2]. Тора-бара түбәтәй төрле катлам ир-атларның көндәлек һәм бәйрәм баш киеменә әверелә.**



Түбәтәй авторлары: Л. Чубукова,
А. Липина, Л.Фәсхетдинова.
ООО «Туран Арт» осталары эшләгән

XIX гасыр урталары – XX гасыр башында татарларда ике төрле түбәтәй булган: ярым сфера рәвешендә дүрт өлгедән тегелгән такыя һәм яссы түгәрәк түбәле кәләпүш. Төрле яшьтәге һәм төрле территориядәге ир-атларның барысы да шушы ике төрнең берсен кигән (керәшеннәрдән башкалар)[3].

Галимнәр такыяның иртәрәк барлыкка килүен әйтә. Күлмәк, ыштан, аякчулар белән беррәттән, такыя да кәләш бирнәсе саналган. Яшьләрне никахлары белән котлаганда: «Такыяң котлы булсын!» – дигәннәр[4]. XVIII гасыр – XIX гасырның беренче яртысындагы рәсемнәрдә түбәтәй-такыяларның түбәсе очлаеп торуын күрәбез. Алга таба ул үзгәреш кичергән. XIX йөз ахыры XX йөз башына караган музей тупланмаларында түбәтәйләр инде ярымтүгәрәкләнеп килгән[5].

Икенче төр түбәтәй – кәләпүшне XIX йөз ахыры – XX йөз башында Казан һәм Казан арты ирләре кия башлаган. Соңрак башка җирлек татарларында да кулланыш тапкан. Кәләпүш төшенчәсенең нигездә Казан артында очравы шуңа бәйледер[6]. Бу төр түбәтәй яссы өслекле, каты кырлы булган. Гадәттә бәрхеттән тегелгән, ефәк җепләр, алтын яки көмеш ука белән, соңрак, энҗе һәм сәйлән белән чигелгән[7]. Кара бәрхет кәләпүш XIX йөз ахыры – XX йөз башында татар милли киеме элементы саналган. Аны кыска кәзәки һәм Европа өлгесендә киселгән чалбар белән кигәннәр[8].

* * *

Ярты гасыр эчендә түбәтәй бизәкләү шактый үзгәреш кичергән: түбәтәйнең төрле тукымадан тегелгән һәм төрлечә бизәлгән күп вариантлары барлыкка килгән[9].

[1] Богословская И. Об особенностях тюбетейки [Электрон ресурс]. – URL:http://fdculture.com/page386539 (мөрәҗәгать датасы: 08.06.2021).
[2] Завьялова М.К. Татарский костюм: из собрания Государственного музея Республики Татарстан. – Казань: изд-во «Заман», 1996. – С. 32.
[3] Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. – Казань: Татар. Кн. изд-во, 1997. – С. 25.
[4] Там же. – С. 24.
[5] Там же. – С. 25.
[6] Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX – нач. XX вв.). – Казань: Фэн, 2000. – С. 72.
[7] Сергеева Н.Г. Татар чигүе – Татарская вышивка. – Казан: Магариф, 2005. – Б. 34.
[8] Мухамедова Р.Г. Указ.соч. – С. 25.
[9] Там же. – С. 24-25.



**Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылы, XVIII-XIX гасыр түбәтәйләре.
З.М. Арикеева (Брусько) фоторәсеме, 2005 ел. «Мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» ДБУ фотофонды, 4 ф., 21 тасв., 7 сакл. бер.**



**Түбәтәй. Яңа Чишмә районының Халык иҗаты һәм Көнкүреше музееннан**

Г. Залкинд билгеләп үткәнчә, XIX йөз ахыры XX йөз башында мул чигешле түбәтәйләргә ихтыяҗ кимегән. Бу Европа киеменең милли киемне кысрыклап чыгара башлавына бәйле. Аз гына чигешле яки бөтенләй чигешсез кара түбәтәйләр киелә башлаган[10].

1950-1970 елларда түбәтәйләр төсле җепләр белән чигелгән. Туксанынчы елларда төсле җепләр урынына сәйлән белән чигү өстенлек ала. 2000 елларда, тегү фурнитуралары төрләре арта башлагач, түбәтәйләрне ялтыравык пайеткалар белән дә бизиләр[11].

* * *

Түбәтәйне нигездә Казан һәм Казан арты кәсепчеләре һәм вак һөнәрчеләре ясый башлый. XIX гасырда кәләпүш кәсебе формалаша. Кәләпүшчеләр Казан кибетләренә елына 50 мең баш киеме китерәләр[12]. Алтын, көмеш һәм энҗе белән чигелгән түбәтәйнең бәясе 2 сумнан башлап 70 сумга җиткән, аннан кыйммәтлерәкләре дә булган[13].

Баш киеме җитештерүчеләрдән сәүдәгәр хатыны Х.М. Апаковаңы билгеләп үтәргә мөмкин. Аның түбәтәйләре 1837 елда I мануфактура күргәзмәсен бизи[14]. XIX гасыр азагында түбәтәй, кәләпүш һәм калфаклар сәүдәсе белән Г. Сабитов фирмасы шөгыльләнә. Казандагы төп сәүдә нокталарыннан тыш, фирманың Нижгар, Минзәлә, Бөгелмә һәм башка ярминкәләрдә филиаллары эшли. Г. Сабитов фирмасында тегелгән баш киемнәре гомумроссия базарында иң яхшылардан санала, Россия һәм чит ил күргәзмәләрендә дан казана. XIX гасырда Лондонда алтын медаль (1884 ел), Амстердамда (1883 ел), Казанда (1886 һәм 1890 еллар), Парижда (1888 ел), Түбән Новгородта (1896 ел) көмеш медаль белән бүләкләнә[15].

[10] Залкинд Г.М. Кустарная промышленность Татарстана. История и процесс производства обуви и головных уборов. – Казань: ТАТИЗДАТ, 1931. – С. 49.
[11] Черных А.В. Традиционная тюбетейка пермских башкир и татар: становление и развитие промысла по изготовлению и орнаментации тюбетеек в Тулвинском поречье // Труды КАЭЭ ПГГПУ. – Пермь. – 2017. – Вып. XIII. – С. 133-141.
[12] Обзор кустарных занятий в Казанской губернии. – Казань: Казанское отделение императорского Русского Технического Общества. – Казань, 1896. – С. 58.
[13] Там же. – С. 59.
[14] Валеева-Сулейманова Г.Ф. Художественные промыслы и ремесла татар в XIX в. // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2011. – №3/4. – С. 42.
[15] Там же. – С. 42-43.



**Түбәтәй авторлары: Л. Чубукова, А. Липина, Л.Фәсхетдинова. ООО «Туран Арт» осталары эшләгән**






**Түбәтәйләр. Авторы Л. Скипина. Д. Петриченко фоторәсеме. Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге фондыннан**

1929 елда Казанда «Азат хатын» дип аталган беренче хатын-кыз кооператив артеле эшли башлый. Артель остаханәсе Яңа татар бистәсендә ике катлы зур булмаган агач йортның өске катында урнаша. Остаханә биш бүлмәне алып тора, аларның дүртесендә осталар утыра, бишенче бүлмә материал һәм әзер товар өчен склад ролен үти. Остаханәдә – 25-30, өйдә 125 кеше эшли.

1920-1930 елларда артель Татпромсоюзның Промысел кооперациясе татар берлегенә карый[16].

Бу елларда кәләпүш кәсебе үзәге нигездә Казанда – Яңа һәм Иске татар бистәләрендә, Сукно, Кизик, Адмиралтейство, Игумный бистәсендә һәм Казан артында – ТАССРның Арча һәм Дөбъяз кантоннарында (хәзер Татарстан Республикасының Арча һәм Биектау районнары) тупланган була[17]. Тарихчы, библиограф, коллекционер Георгий Залкинд тикшеренүләренә караганда, Казанда бу һөнәр белән 896 кеше (288 – хатын-кыз, 608 – ир-ат) шөгыльләнгән. 1929 елда шуларның 234е остаханәләр оештырган Таткустпромсоюз кооперациясенә кергән[18].

Узган гасырның кырыгынчы еллар азагында һәм илленче елларда СССРда түбәтәй кию нык популяр була. Аны төрле милләт кешеләре яратып кия – түбәтәй халыклар дуслыгының бер символы булып тора. СССР таркалгач, Россиядә түбәтәй яңарыш кичерә, тик ул халыкка ир-ат дини киеменең бер өлеше буларак әйләнеп кайта.

[16] Залкинд Г.М. Указ. соч. – С. 53.
[17] Протокол заседания Художественно-экспертного совета Республики Татарстан по народным художественным промыслам № 82 пр от 28.12. 2009 г.
[18] Залкинд Г.М. Указ. соч. – С. 22-23.





**Түбәтәй авторлары: Л. Чубукова, А. Липина, Л.Фәсхетдинова. ООО «Туран Арт» осталары эшләгән**

* * *

Безнең көннәрдә түбәтәй кечерәк предприятиеләрдә, акционерлык җәмгыятьләрендә һәм аерым осталар тарафыннан җитештерелә. Мәсәлән, Казанда «Болгар түбәтәе» студиясе 2000 еллар башыннан бирле түбәтәй тегә. 2015 елда алар Миланда узган халыкара күргәзмәдә (Esposizione Universale Milano 2015, Expo 2015) катнаша.


«Тукай түбәтәе» остаханәсе дә түбәтәйләр тегә. Остаханә бөек шагыйребез Тукай исемен алган. Чөнки Тукайның зәвык белән киенүе, образын кара кәләпүш белән тулыландыруы билгеле. Кәләпүш XX гасыр башында татар интеллигенциясенең яраткан баш киеме була.

Соңгы елларда Казанда түбәтәй җитештерү кызыклы үсеш этабын кичерә. Бер яктан осталарга массакүләм җитештерелгән баш киемнәре белән ярышырга туры килә – бигрәк тә, машина белән чигелгән юка төрек түбәтәйләре көчле конкуренция тудыра[19]. Шул ук вакыта Казан осталарының иҗади эзләнүләре бу һөнәрнең югалмавын дәлилли. Әйтик, шуның бер мисалы буларак, 2000 елларда ак туй түбәтәйләре күренә башлый – яңа төр түбәтәйләрнең барлыкка килүенә кияүнең ак костюм кия башлавы сәбәп була.

Җыеп әйткәндә, һөнәрчелекнең бүгенге этабы милли түбәтәебезне кырыс конкуренция шартларына куя, әмма бирешмичә сакланып калу юллары бар һәм без шушы юлда дип ышаныйк.

[19] Черных А.В. Указ. соч. – С. 139.

# *Бергәләп бизибез!*



# *Илсөяр Закирова:*
# «Безнең якта соңгы Чабыр бәйрәме 1940 елда узган»

*Илсөяр ЗАКИРОВА,*
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының халык иҗаты*
*бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

**Тау ягында урнашкан Кама Тамагы районында яшәүче халык борын-борыннан уңган, бу якларча әйтсәк «чирак» булулары белән тирә-юньгә танылган. Шул ук вакытта алар ял да итә белгән, ягъни, бәйрәм һәм эш аралашып барган. Элеккеге Сабантуйлары, Чабыр бәйрәмнәре турында мин әби-бабайлардан балачактан ишетеп үстем.**



Сабан туе ул Җир ананы һәм туфракны хөрмәтләү, аларга рәхмәтле булу, игенченең җир эшләренә керешер алдыннан күңелен күтәрү. Барыбыз да беләбез, әгәр яхшы кәеф, тыныч күңел белән башламасаң, пешергән ризыгың да уңмаска мөмкин. Язгы чәчү, уңыш җыю кебек зур эшләр бигрәк тә. Шуңа күрә, Сабан туе ул беренче чиратта, заманча әйтсәк, кешенең күңел халәтен уңай вибрацияләргә көйләү, Җир ана белән кеше арасында гармония булдыру.

Тау ягында Сабан туе карлар эреп, сукмак төшә башлагач, язгы кыр эшләренә керешер алдыннан уздырылган. Бәйрәмгә дип һәр балага, яшь кызга һәм егеткә яңа кием тегелгән яки алынган. Сабан туена суеласы тәкәне дә берәр ай кала аерып ашата башлаганнар. Яшь егетләр чабышка атларын әзерләгән. Чормалардан Сабантуйга дип тәгаенләгән каклаган казлар төшкән, берничә көн







алдан камыр ашлары әзерләнә башлап, бәйрәм иртәсе коймак һәм юка-төш пешерү белән башланып киткән.

Сабан туена махсус эчемлек – «почти градуссыз» буза куйганнар, һәм «градуслы» бал әчеткәннәр. Татарда исерткеч эчемлек булмаган, дип әйтергә яратабыз. Бу фикердә дә хаклык бар. Өлкәннәр сөйләве буенча, бузаның башта максымасын агызып алганнар. Шушы ук информантлар сөйләвенчә, «дөньяда аның кебек тәмле эчемлек юк та, була да алмый». Бузаның рецептын кат-кат сорашып карасам да, төбенә төшә алмадым. Арыш саламы, арпа, тагын әллә нәрсәләр кушылып, тишекләре камыр белән томаланып, махсус чүлмәкләрдә хәзерләнгән буза һәм максыманың рецепты әбиләребез белән бергә китеп барды. Балның составында чиста бал белән чыгыш суы гына булуына карамастан, ул башка китмәсә дә, аякларның хәлен алган. Буза һәм максыманы – хатын-кызлар, балны фәкать ирләр генә эчкән.

Сабан туеның алдагы көнендә мунча ягылып, һәр кеше мәйданга чиста тән, чиста уй һәм чиста кием белән юнәлгән.

### САБАНТУЙ

*Сабантуйны чәчүгә төшкәнче, сукага чыкканчы үткәрәләр иде. Пычрак була иде әле. Мулла көнен билгеләгәч, балаларга: «Бар, өндәгез», – диләр иде.*

*Ир малайлар җитәкләшеп урам тутырып Сабан туена өндәп баралар. Өч-дүрт йорт саен туктап: «Иртәгә Сабан туе, белен-коймак изегез», – дип кычкыралар. Алардан 5-6 йорт артта ир-егетләр гармуннар уйнап, җырлап җаулык җыя. Җиткән кызлардан чиккән кулъяулык, килгән киленнәрдән чиккән сөлге алалар. «Сөлгесе бик матур булган, фәләнгә эләккән», – дип сөйлиләр иде аннары. Күбесе йомырка бирә, сөлге-тастымал бирүчеләр аз була. Авылның берәр бае батырга дигән тәкәне бирә. «Быел фәлән бирә, тәкә ашатып тора икән Сабан туена», – дип сөйлиләр иде.*

*Җаулык җыючы егетләр артыннан бик кечкенә кызлар ияра.*

*Иртәгесен иртүк, Сабан туена барганчы, йомырка буйыйлар. 9-10 яшькә кадәрге кызлар махсус тегелгән букчаларын*

**Сабан туеның алдагы көнендә мунча ягылып, һәр кеше мәйданга чиста тән, чиста уй һәм чиста кием белән юнәлгән.**

*күтәреп буялган йомырка, кызыл билле прәннек, конфет, кара кузак җыя. Хуҗалар бирәсе бүләкләрен табакка өеп әзерләп куйган була.*

*Башта бер авыл карты Коръән укып, Сабантуйны башларга рөхсәт бирә. Сабан туенда гармун уйныйлар, әмма җыр-бию булмый. Сабан туе кичкә кадәр дәвам итә.*

*Кич белән кызлар-егетләр Таккаравыл уйнарга чыгалар иде. «Бүген Таккаравыл уйнарга чыгабыз», – дип, пышын-пышын сөйләшәләр иде.*

**(Хания Фатыйх кызы Хөсәенова (1928 елгы), Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы, 2006 елда язып алынды.)**

Тора-бара Сабан туе колхозда язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң уздырыла башласа, соңгы елларда ул алдан язылган сценарий буенча уздырыла торган шоуга әверелеп, җиргә һәм җир эшләренә бәйләнешен тулысынча җуйды. Үзе дә җирдән һәм җир эшләреннән читләштерелгән, кырларында шаулап иген үсмәгән, язын туфракны кулына алып өлгергәнлеген тикшермәгән, кырга чыккач, башак өзеп кабып караудан мәхрүм калган халык өчен бүгенге көндә бу табигыйдыр.

* * *

Бу якның икенче зур бәйрәме – Чабырның, Сабан туеннан аермалы буларак, көне төгәл билгеле: ул уракка төшәр алдыннан 14, 15, 16 июльдә (яңа стиль белән) уздырыла. Тау ягында Чабыр бәйрәме соңгы тапкыр 1940 елда узган.

**ЧАБЫР**

*Чабыр җитә дип көтеп торалар иде. Чабыр тавына бөтен авыллар – урысы-татары җыела. Атлар җигеп баралар. Атларга калакуллар* тагалар, аларны кулъяулыклар белән бизиләр. Ике кәмит була иде. «Гәрәчи» ** пешерәләр. Кешеләр табыннар*

* Калакул — колокол, кыңгырау.
** Гәрәчи — горячий сүзеннән.










*корып утыра, туганнар-танышлар бергә җыелышып утыра. Чабырга дип кешеләр үзләре ясаган сыра эчәләр иде.*

*Яшьләр биешеп-җырлашып, гармуннар белән утыралар.*

*Чабырдан кайткач, яшьләр түбән чирәмгә төшеп китәләр иде. Ул көн яшьләр болында күңел ачалар, уеннар уйныйлар.*

**(Асия Харис кызы Шаһиева (1926 елгы), Кама Тамагы районы Олы Бортас авылы, 2004 елда язып алынды.)**

* * *

*Чабыр безнең якта, Бәки белән Келәнче авыллары арасында, тау башында – Чабыр тауда булган. Анда атлар белән бөтен якын-тирә авыл халкы җыелган.*

*Чабыр өч көн булган: Чабыр башы көне, Урта Чабыр көне, Актык Чабыр көне дип йөрткәннәр. Ул 14, 15, 16 июньдә үткән – хәзерге яңа стиль белән 1 июльгә туры килә.*

*Чабырда уен булмаган, Ат кәмите генә килгән. Кәмиттә кара-каршы ике-ике утыргычлар, карага буялган атлар булган. Яшьләр, балалар атланып утырган. Бер билет белән өч тапкыр әйләнгәннәр. Уртада шалашы булган. Шуның тирәсендә музыкантлар төрле уен коралларында уйнап утырган. Өч кәмит килә торган булган. Бик күп кибетләр килгән.*

*Авыл халкы гәрәчи пешергән. Аны әче камырны, суга изгән камырны казандагы кайнап торган майга салып пешергәннәр. Кызыл су сатканнар.*

*Чабырга баргач, кешеләр атларын туарган, тәртәләрен күтәрткән. Атны тәртә арасына кертеп бәйләгәннәр. Торыпша җәйгәннәр. Бала-чага арба астында утырган. Бала-чага күп булган. Аларга түгәрәк көмәч алып биргәннәр. «Беркая китмәгез, ату адашасыз, аннары табып булмый сезне», – дип куркытканнар.*





Авыл халкы гәрәчи пешергән. Аны әче камырны, суга изгән камырны казандагы кайнап торган майга салып пешергәннәр.

Автор фоторәсемнәре

*Кеше ашап-эчкәч, сатасын саткач, кирәк әйберен алгач, акчасы беткәч, кайтып киткән. Чабырда итекләр, орлыкка бәрәңге һәм башкаларны алганнар.*

*Сугыш башлангач Чабыр бәйрәме тукталган.*

**(Хания Фатыйх кызы Хөсәенова (1928 елгы), Кама Тамагы районы Олы Кариле авылы, 2006 елда язып алынды.)**

Соңгы вакытта, колхозлар юкка чыгу белән, авыллар гына гына түгел, бәйрәмнәребез дә онытыла бара. Кама Тамагы районының Балчыклы авылы – бәйрәмнәрен саклап, күркәм йолаларын торгызып, традицияләрен хөрмәт итеп яшәгән авылларның берсе. Биредә халык ел саен Сабан туена туры китереп ялга кайта, тирә-яклар «кунакка килә». Колхозлар беткәннән соң тукталып калган Сабантуйларын шушы авылда туып үскән өч ир-егет яңадан халыкка кайтара. Сабан туе шушы өч меценат – Илһам Шиһапов, Илдар Шиһапов һәм Илнар Кәлимуллинның матди ярдәме белән оештырыла. Илнар Сабан туе иганәчеләренең берсе булуы өстенә, бәйрәмне оештыруны да үз өстенә ала.

Быелгы бәйрәм буена халык алдында җырчы Рөстәм Закиров гаиләсе белән, башка билгеле җырчылар үз репертуарларыннан җырлар башкарды.

Көрәшне балалар башлап җибәрде. Гомумән, һәр ярышны, һәр уенны балалар башлап, аларга бәйрәмнең асылы сеңдерелә бара. Илнар әледән-әле авылдашларын үсендереп, аларны мактап, Балчыклы балаларын актив булырга чакырып, бу бәйрәмнең, беренче чиратта, алар бәйрәме булуын искәртеп торды.

Сабан туена килүчеләрне мәйдан, уеннар, җыр-музыка һәм ярышлар гына түгел, мул табын, тулы өстәлләр, кайнар пылау, тәмле чәй дә көтә иде. Шул рәвешле бәйрәмгә килгән һәр кеше үзен кунактагыдай хис итте.

# КИЛЕН ТӨШӘ *бүген авылга...*

**(ТУЙ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕНӘ БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ)**

*Алсу ӘСКӘРОВА,*
*Әтнә үзәк китапханәсе*
*җитәкчесе*



*Мамык мендәрләргә төренеп,*
*Килен төшә бүген авылга.*
*Борынгыдан калган гадәт ул –*
*Авыл чыккан каршы алырга,*
*Яшь кәләшне күреп калырга...*



**Халык шагыйре Роберт Миңнуллин йортка килен төшүне шигъри юлларга салып шулай тасвирлаган, күренекле композиторыбыз Рөстәм Яхин аңа көй язган.**

Нәкъ шушы җырдагыча, кияү йортына килен төшерү элек-электән бөтен авыл өчен зур бәйрәмгә әйләнгән. Хәтерләсәгез, әле кайчан гына туй буласы йортның капка төбенә бөтен авыл халкы килен төшкәнне карарга җыйнала иде. Бу күркәм гамәлгә бәйле күпме гореф-гадәтләребез бар – кыз ярәшү, кыз сорау, кызга бирнә әзерләү, никах укыту, никах туе, кияү мунчасы, килен токмачы, өй киендерү, киленгә су юлы күрсәтү... Халыкта бу йолалар белән бәйле күпме әйтемнәр, ырымнар, ышанулар, юрамалар да яшәп килә.

Кыз сорау йоласы элек ничек булган? Килен-нең бирнә сандыгына ниләр салынган да, бүгенге татар кызы бирнәсендә нәрсәләр булырга тиеш? Өй киендерү йоласы ничек башкарылган? Кияү мунчасы ягу кемгә йөкләнгән? Киленгә су юлын күрсәтү кирәкме? Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә бу йолалар бер-берсеннән аерылып торамы? Алар бүген дә саклангапмы?..

Әтнә үзәк китапханәсендә оештырылган «Килен төшә бүген авылга...» кичәсендә шушы сорауларга күпмедер дәрәҗәдә җавап ишеттек кебек: онытылып барган йолаларны өлкән буын вәкилләренең үзләреннән сөйләтә алдык. Кичәбезгә төрле буын вәкилләре – озак еллар пар канатлы булып тигез гомер кичергән ак әбиләр, төрле яшьләрдәге ханымнар һәм туташлар катнашты. Башка җирлектәге гореф-гадәтләрне барлау йөзеннән, Әтнәгә күрше-тирә районнардан, хәтта күрше республикалардан килен булып килгән ханымнарны да чакырдык. Кичәбез кунаклары – 40-50 ел элек килен булып килгән ханымнар – үзләрен ничек сорый килүләре, кичләрен бирнәлеккә сөлге, карават җәймәләре, мендәр тышлыклары, аяк чолгаулары чигүләре турында истәлекләре белән уртаклаштылар. Килен булып төшкән көнне авыл башына җиткәч, җигелгән кыңгыраулы пар атка, бизәлгән тарантасларга күчеп утырып, гармун уйнап авыл урамнарын әйләнүләрен сагынып искә алдылар.

## КЫЗ СОРАРГА КИЛҮ ЙОЛАСЫ

– Без өйләнешәбез!

Тормышның өр-яңа баскычы бүгенге гаиләләрдә шулай башлана: кыз белән егет гаилә корырга булган, хәтта никах һәм туй көне дә тәгаенләнгән – ике яктагы әти-әнигә моның белән килешәсе генә кала. Димләү, яучы җибәрү кебек йолаларның кирәге калмады кебек. Әмма элеккеге гореф-гадәтләр тормышыбыздан бөтенләй юкка чыкты дия алмыйбыз. Әйтик, егет ягыннан «Кыз сорарга килү йоласы» бүген дә бик күркәм гадәт. Кыз баланы кадерләп үстергән ата-анага хөрмәт күрсәтү, аларның ризалыгын, фатихасын алу дигән сүз бу. Ә бит элегрәк татар халкында кызны урлап алу, ябышып чыгу очраклары да булган. Ләкин алар, аерым очраклардан башка,

халыкта хуплау тапмаган. Димче җибәреп, ярәшеп, туйлап өйләнү яки кияүгә чыгучыларны үрнәк итеп сөйләгәннәр.

## НИКАХ

Туй гадәттә никахтан башлана. Никах – туйның иң мөһим вакыйгасы, изге гамәлләрнең берсе булып тора.

Никах мәҗлесе кыз өендә үткәрелгән. Табын артында гадәттә егетнең һәм кызның иң якын ир-ат туганнары утырган. Мулла, никах укыганчы, кызның мәһәре турында сорап, махсус кенәгәгә теркәп куйган. Шуннан соң гына, кызның ризалыгын алып, никах догасын укыган. Табынга никах ашы итеп бал-май, баллы су – ширбәт куелган. Ул «никах суы», «никах ширбәте» дип йөртелгән. Никах укылгач, баллы суны кызга да, кияүгә дә йоттырганнар, кунаклар да авыз иткән, «тормышлары татлы, балдай-майдай булсыннар» дип, «ширбәткә» дип парлап-парлап тәңкәләр яки бүләкләр салганнар. Никахтан соң кияү, тормышлары парлы булсын өчен, кәләш йортында парлы төн кунган.





## ӨЙ КИЕНДЕРҮ ЙОЛАСЫ ҺӘМ БИРНӘ БАГУ МӘҖЛЕСЕ

Никах туе яки туй мәҗлесе үткәннән соң кияү йортында бик күркәм «Өй киендерү йоласы» башкарылган – яшь килен бирнәгә алып килгән әйберләре белән өйне бизәгән.

Элек-электән, кыз бала тууга, әти-әнисе бирнә әзерли башлаган: мендәрен-юрганын, пәрдә-чаршау, сөлге-тастымал, ашъяулыгын сандыкка салган. «Кыз – бишектә, бирнә – сандыкта» дигән әйтемнең нигезендә шул ята. Кыз бала, әнисеннән-әбисеннән яки, аулак өйләргә утырмага барып, башка хатын-кызлардан кул эшләренә өйрәнгән һәм үзенә бирнә әзерли башлаган. Бирнә сандыгында кыз баланың байлыгы – кияүгә, аның әти-әнисенә һәм туганнарына алып килгән бүләге, йорт киендерү кирәк-яраклары булган. «Бирнә биргән – бикә килен, бирнә бирмәгән – чәүкә килен» дигән борынгылар.

«Бадьян да салдым акмаска,
Кәнәферләр салдым батмаска, –
Бу әйберләрне без әләбез –
Берсе дә кире кайтмаска», – дип җырлый-җырлый, яшь кызлар киленгә өйне киендерергә булышкан. Өй килен алып килгән тәрәзә пәрдәләре, чиккән сөлгеләр, чаршау-чыбылдыклар, әлмәләр белән бизәлгән. Килен бирнәсен күрергә, бизәлгән өйне карарга, бәяләргә, бүләкләр күтәреп, тирә-күрше, туган-тумача кергән. Элеккеге заманнарда «Бирнә багу мәҗлесе» йоласы да булган. Шул рәвешле авыл киленнәре яшь киленне үз араларына кертеп җибәргән.

Килен сандыгы, гадәттә, йортның түрендә урын алган. Сандыкта башта яшь киленнең туган йортыннан килгән кадерле әйберләре сакланса, бераздан аларны бәби киемнәре алыштырган. Хуҗасы олыгая барган саен сандык аның яшьлек хатирәләрен үзенә җыйган…

Кызганыч, бүгенге көндә бирнәне сандыкка тутырып алып бару, «Өй бизәү йоласы» юкка чыгып бара диярлек.

## КИЛЕН КАРШЫЛАУ ЙОЛАСЫ

Ниһаять, туй көне җитә. Авылны шаулатып килен төшә. Туй атларын бары туйлар өчен генә тотыла торган, тәңкәләре ялтыратылган затлы



дирбияләр белән кышын яхшы чанага, җәен тарантаска җиккәннәр, дугага кыңгыраулар, кызыл башлы сөлгеләр элгәннәр. Туй атларына һәрвакыт юл биреп узганнар. Әби-бабалардан калган гадәт буенча, киленне авылны әйләндереп, көнчыгыш яктан кайтып керергә тырышканнар. Бу гамәл яшь парны явыз көчләрдән саклау, юлны бутау максатыннан эшләнгән. Атлар җигеп, авылны гөр китереп килен төшерүләр дә бүгенге көндә җырларда гына җырлана.

«Киленне кияү өендә каршы алу йоласы»да бик матур узган. Кияү белән кәләш аттан төшүгә яисә баскыч төбендә киленне ак мендәргә бастырганнар. Килен мендәргә уң аягы белән басып, өйгә кергәндә мендәрен кулына алып, егет артыннан калмыйча керсә, уңган, эшчән булыр, әгәр мендәрне алмыйча, атлап кереп китсә, булдыксыз, ялкау булыр дип юраганнар. Халыкта, үз артыңнан мендәреңне алмасаң, гайбәт, юк-бар сүзләр сөйләрләр дигән ышану да бар.

Егет йортына кергәч яшь киленгә бал-май каптыру – «Киленне авызландыру йоласы» башкарылган. «Төкле аягың белән», «Май кебек йомшак, бал кебек татлы телле булыгыз», – дип әйтеп, каенанасы улына-килененә бал-май каптырган, ягъни, авыз ачтырган. Әлеге йолалар бүгенге көндә дә яшәп килә.

Безнең Казан арты авылларында килен кеше бусагадан керүгә иң беренче мичкә карарга тиеш дигән ырым булган. Мич өйнең уртасында торган, яңа килгән яшь килен дә тиз арада шушы өйдәге гореф-гадәтләрнең серенә төшенсен, үзәгенә керсен, янәсе. Әнисе яки апалары кызны алдан ук: «Өйгә кердеңме, мичкә кара, тәрәзәгә карама, тәрәзә яшьле була, мич гомерле була», – дип кисәтеп куйганнар. Кияүгә киткән кызга артына борылып карарга ярамый дигән ышану да киң таралган, имеш, артына борылып караса, кияүдән кире кайта. «Төшкән җиреңдә таш бул!» яисә «Барган җиреңдә таш бул, таш бул да аш бул!» – татар халкының ерак дәверләрдән килгән, гаилә кыйммәтләрен саклауга юнәлтелгән теләкләрнең берсе. Гаиләгә бәхет, муллык китерү теләп, яшь киленнең өстенә ашлык та сипкәннәр. Кайбер якларда тормышлары ризыклы, мул булсын өчен киленнең ике кулын онга батырып алганнар.

## КИЯҮ МУНЧАСЫ

Туй йоласының тагын бер өлеше – кияү мунчасы. Гореф-гадәт буенча туй иртәсендә кияү мунчасы ягыла. Гадәттә мунчаны кияүнең берәр якын туганы яга. Ул яшь парлар кергәнче мунчаны чит-ят кешеләрдән саклап тора. Яшьләр мунча ягучыга рәхмәт, ихтирам йөзеннән, мунча тәрәзәсе төбендә бүләк яисә акча калдыра. Безнең Әтнә районының кайбер авылларында яшьләрнең мунчадан чыкканын көтеп тору гадәте дә бар. Яшьләрне кыш көне ләгәнгә, җәй көне арбага утыртып, ишегалдын әйләндереп өйгә алып керәләр. Мунчага барыр юлда киленне сынау гадәте дә еш таралган. Мәсәлән, мунчага илтә торган сукмакка нинди дә булса эш коралы – кисәү, себерке, балта, сәнәк ташлыйлар, һәр әйберне билгеле бер кеше ташлый – җиңгәсе, кайнише һәм башкалар. Сынап торалар: килен кайсын алып куя, сөяп куя, кертеп куя, кияүгә алып бирә... Әллә атлап яисә таптап, тибеп кенә узамы? Менә шуларга карап киленнең холкын әйтәләр. Юлда яткан коралларны алып куймаса: «Бу өметсез яисә ялкау булыр, ире белән тора алмас», – дип юрыйлар.

* * *

Шулай итеп, татар халкының иң матур йола-гадәтләренә нигезләнгән туй мәҗлесләре узгач, яшь кыз бөтенләй башка югарылыктагы гомер баскычына аяк баса. Аңа инде, әти-әни йортындагы кебек, «кызым» дип түгел, күбрәк «килен», «хатыным» дип, балалары тугач, «әнисе» дип эндәшә башлыйлар, иренең туганнары «җиңги», «туган апа» дип йомшак сүз белән мөрәҗәгать итәләр. Болай эндәшү гаиләдә җылы мөнәсәбәт тудыра, якынлык барлыкка китерә. Килен дә иренең әти-әнисенә «әти-әни», «әткәй-әнкәй» дип эндәшергә, җылы сүзен кызганмаска, матур мөгамәләдә булырга тиеш. Кияү исә кәләшнең әти-әнисенә «әби-бабай» дип дәшә. Яңа татар гаиләсенең тормышы менә шул рәвешле башлана.

## ТУЙ КҮЛМӘКЛӘРЕ КҮРГӘЗМӘСЕ

Кичә барышында өлкән апаларыбыз бик дулкынланып, яшьлекләрен сагынып, туй хатирәләре белән бүлештеләр, халкыбызның

йолаларын, гореф-гадәтләрен искә алдылар, яшь буынга үгет-нәсыйхәтләрен, файдалы киңәшләрен җиткерделәр, үзләре белән алып килгән туй күлмәкләренә бәйле матур истәлекләре белән дә уртаклаштылар.

Туй күлмәкләреннән күргәзмә дә оештырылды. Араларында 30, 35, 40, 48, хәтта 76 ел элек киелгән күлмәкләр дә бар иде. Күптәнге булсалар да, туй күлмәкләре матурлыгын, аклыгын югалтмаганнар, яхшы сакланганнар, чөнки апалар күлмәкләрен кадерләп саклаганнар.

* * *

Әлеге кичә борынгы йолаларны бүгенге көн туй йолалары белән чагыштыру мөмкинлеге бирде. Баксаң, бик күп йола, гореф-гадәтләребез бүгенге көнгә кадәр сакланып килгән. Никах-туй мәҗлесләре үткәрү кафе-рестораннарга күчеп барса да, бизәлгән машиналар белән авыл әйләнү, киленне мендәргә бастыру, бал-май каптыру, кияү мунчасы ягу кебек йолалар үтәлә, авыл җирендә бигрәк тә. Йолаларыбыз, заманага яраклашып, яңа төсмерләр алып, бераз үзгәреш кичерүгә карамастан, аларның милли асылы, төп мәгънәсе саклана.

### *КИЛЕН ТӨШКӘНДӘ*

*Роберт Миңнуллин сүзләре,*
*Рөстәм Яхин көе*

*Ак күбеккә баткан юргалар*
*Кышкы юлдан ярсып чабалар.*
*Чак-чак кына аумый калалар*
*Салулаган чакта чаналар,*
*Арттан чаба бала-чагалар.*
*Мамык мендәрләргә төренеп,*
*Килен төшә бүген авылга.*
*Борынгыдан калган гадәт ул –*
*Халык чыга каршы алырга,*
*Яшь кәләшне күреп калырга.*
*Җилкендереп ять-яшь кызларны,*
*Килен төшә бүген бер өйгә.*
*Кайда калды шундый чагым, дип.*
*Авыр сулап куя әниләр,*
*Авыр сулап куя әбиләр.*
*Күптән инде ачып куйганнар*
*Килен төшкән өйнең капкасын.*
*Килен төшкән өйнең капкасын*
*Китәргә дип кире япмасын,*
*Кайгы җиле килеп какмасын.*



Фоторәсемнәр Аделина һәм Алмаз Нигъмәтуллиннарның шәхси архивыннан

# ХАЛЫКНЫҢ *сәнгати ачышы*

*Людмила ШКЛЯЕВА,*
*сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

**Мөдәррис Минһаҗев иҗатын татар тарихы һәм мәдәнияте темаларын ачуга багышлаган күренекле рәссам. Глобализация аркасында сүнеп барган үзенчәлекле сәнгать проблемалары борчый аны. Чит эстетик кыйммәтләрне белер-белмәс кабул итү – милләтнең югалуына китерүен аңлап йөрәге яна. Үзенең масштаблы картиналарына ничек тә булса милли бизәкләрне, үз мәдәниятенең визуаль образларын күчереп калдырырга омтыла.**



«Учак». 2022 ел

Бу образлар рәссамга балачактан таныш. Ул татар йорты интерьерын күңеленә сеңдереп үскән: пәрдәләр, мендәр тышлары, челтәрләр, диварлардагы паннолар – әйтерсең лә, тылсымлы бакча фрагментлары. Аларның һәрбесендә әнисенең яки әбисенең оста куллары белән гөлләр-чәчәкләр чигелгән һәм үрелгән. Көзге читенә чүпләмле сөлге эленгән. Аның бизәкләре, тормышның кабатланулы булуын искәртеп торгандай, симметрияле итеп тукылган. Тәрәзә йөзлекләре дә, капка да агачтан бизәкләп ясалган – болары әтисе белән бабасы тырышлыгы. Авылдагы башка йортлар да шулай бизәлгән. Бу бизәкләр Мөдәррис Минһаҗевны гомере буе озата барып, гаилә, туган җир һәм татар халкы образлары белән тәңгәлләшкән.



Рәссам Мөдәррис Минһаҗев





«Болгарны саклаучыларга багышлана». 2018 ел

«Саба бизәге». 2017 ел

Үсеп, белем алгач, ул чигүчеләр, тукучылар, балта осталары һәм башка халык һөнәрчеләре бизәкләрнең камил формаларын һәм композицияләрне кайдан алуы белән кызыксына башлый. Сораша торгач шул ачыклана: әниләр – кызларын, аталар улларын өйрәтә икән. Димәк, бизәкләрне аларны ясаучы уйлап тапмаган, буыннан буынга килгән, ягъни, бизәкләр аша борынгы бабаларыбыз тарафыннан киләчәккә юллама җибәрелгән.

Мөдәррис Минһаҗев татар бизәгенең чыганаклары белән кызыксынып, фәнни әдәбиятка мөрәҗәгать итә. Урта Идел буе татарлары мәдәниятенең XVIII гасырдан башлап, Европа галимнәренең игътибарын җәлеп иткән орнаментлары иң беренче булып, Россиянең танылган сәнгать белгече, рәссам П.М. Дульский (1879-1956) тарафыннан комплекслы һәм системалы өйрәнелүен белеп, аның хезмәтләре белән кызыксынган. Болгар төзелешләрен бизәү элементларын татар осталары үзләренең декоратив-гамәли иҗатында XX гасыр башына кадәр кулланган икән. П.М. Дульский 1923 елда Арча кантонының Кече Рәс, Татар Алты, Олы Әтнә, Олы Мәңгәр, Каймар, Шушар авылларына экспедиция материалларына таянып шундый нәтиҗәләргә килгән. Ул татар нәфис сәнгатен өйрәнүче белгечләр арасында шушы җирлектән чыккан татар галимнәре булачагына ышанган.

Нәкъ ул фаразлаганча, Фуат Вәлиев килеп чыга, ул татарның беренче сәнгать фәннәре докторы. Традицион татар сәнгатенә багышланган хезмәтләре белән символлар һәм образлар аша халыкның тарихи хәтерен саклаучы орнаменталь системага анализ



ясаучы да ул була. Сәнгать белгечләре Ф.Х. Вәлиев, Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова, Р.Р. Солтанова һәм алардан соң килгән галимнәр татар орнаментының зур төрки дөньяның декоратив системасы һәм бүгенге татарларның борынгы бабалары булган төркиләрнең гамәли иҗаты белән элемтәсен ачыклады. Әйтик, мөгезсыман бөдрәләрнең симметрик пары терлекчелеккә бәйле көнкүрешкә барып тоташа – Алтайның Пазырык курганнарындагы мәңъеллык табылдыклар шул хакта сөйли. Тәкә мөгезе яшәү чыганагын искәртә. Үрелгән бизәкләр күчмәлек чорында чыдамлык өчен йортларын тотып торган агачларны урап ныгыткан бауларга барып тоташа. Бу техник алым күчмә халык тарафыннан йортның визуаль образының һичшиксез булырга тиешле компоненты кебек кабул ителгән һәм алдагы буыннар тарафыннан баулы орнамент рәвешенә кертелгән, хәзер ул татарларның гамәли сәнгатендә кулланыла.

Алар Урта Идел буенда утрак тормыш белән яши башлагач та металлдан, күннән, йоннан, агачтан һәм башкалардан ясалган көнкүреш һәм культ әйберләрен бизәгәндә таныш орнаментларны кулланган. Борынгы Болгарның декоратив-гамәли сәнгатендә табигать көчләренең торгызылуын тасвирлаучы лалә чәчәге прототибы булган трилистник күзәтелгән.

Мөдәррис Минһаҗев болгарларның декоратив системасына кергән һәм дөньяга карашын чагылдырган орнаменталь сәнгатьнең тотрыклы нигезләре турында әлеге мәгълүматларны җентекләп өйрәнә. Үзенчәлекле бизәкле композицияләрнең тарихи кануннар нигезендә төзелүенә һәм буыннан буынга бүгенге татарларга килеп җитүенә инана.

**«Борынгы җыр». 2016 ел**

**«Үз көебез». 2019 ел**








«Мирас». 2019 ел

«Әүлия кабере». 2016 ел

Татарларның орнаменталь системасындагы мөселман компоненты рәссам өчен аеруча кыйммәткә ия. Идел буе Болгар дәүләтенең Ислам динен кабул итүе татарларның борынгы бабалары өчен мәдәният үсешенең яңа этабы була. Бу инде мөселман сынлы сәнгать кануннары тәэсирендә формалашкан сәнгать. Ислам Урта гасырлар болгар җәмгыятенең, соңрак феодаль үсеш кичергән Казан ханлыгының идеологик һәм сәяси таләпләренә туры килә. Мөдәррис Минһаҗев мөселман карашларының татарларның этник мәдәниятенә тирән үтеп керүенә дәлилләр таба, бу беренче чиратта аниконизмда, ягъни сакраль сәнгатькә мөнәсәбәттә һәм каллиграфиядә, шулай ук, бизәкләү һәм шартлы декоративлык сәнгате принципларында ачык чагыла. Бигрәк тә декорда җәннәтне күзаллаулар белән бәйле чәчәк-үлән мотивлары киң таралган.

Рәссам үз иҗатында формалары гасырлар дәвамында камилләшкән һәм үткән гасырның җитмешенче елларына килеп җиткән үзенчәлекле бизәкләргә мөрәҗәгать итеп, үз эшләрендә аларның җәлеп иткеч гүзәллеген күрсәтә алды. Иҗат әһеле халык һөнәрчелегенең һәм орнаменталь сәнгатьнең онытыла баруына борчылып, моңа җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итәргә тырыша. Аның өчен татар бизәкләренең сәнгати образлары милли тәңгәллегебез билгеләрен эзләүгә, этник чыгышыбызны символик чагылдыруга тиң. Бу мәдәни кыйммәтләребезне киләчәк буынга ирештерүнең бер юлы була ала. Мөдәррис Минһаҗевның әсәрләрен милли мәдәниятебезнең визуаль билгеләрен яңа заманга кайтару дип кабул итәргә мөмкин. Аның картиналарында «халыкның сәнгати ачышы» булган әлеге орнаменталь мотивлар яңара.



«Яшьлегем бизәкләре». 2017 ел

Фоторәсемнәр Мөдәррис Минһаҗевның шәхси архивыннан

# Авылымның ямьле кичләре

Кайбыч районында җиденче тапкыр уздырылучы «Кичке уен» фестивале елдан-ел популярлаша бара. Быел ул Россия халыклары мәдәни мирасы елына багышланган иде.

– «Кичке уен» – Кайбычның бренды ул. Аны республика масштабына чыгару өчен тырышабыз. Бу матур бәйрәм күпмилләтле районыбызның барлык авылларында да узды. Әлеге чараны үзләрендә үткәргән барлык мәдәният хезмәткәрләре бүген шушы зур мәйданга җыелды, – дип сәламләде район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин.

Ул көнне авыл урамнарында йөрүчеләр мондый матур күренешкә таң калгандыр. Урам тутырып, иң алдан түбәтәйле-камзуллы гармунчылар килә, халкыбызның күңел түреннән өзелеп төшкән көйләрен уйнуйлар, аларга милли киемле үзешчән җырчылар кушыла.

Мәдәният бүлеге житәкчесе Рамилә Әбләзова тәкъдиме, тырышлыгы белән районыбызда башланып киткән «Кичке уен» проектының тарихын барлыйбыз.

– Элек яшьләр кичке уеннарда, кич утыруларда танышканнар. Шул уеннарда гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклаганнар. Казан мәдәният институтын тәмамлап районга эшкә кайткач, «Кичке уен»нарны торгызу турында уйлана башладым. 2013 елда башлап җибәрдек без аны: башта авылларда уздырдык. 2015 елдан зурлап, район күләмендә үткәрәбез. «Эшләгез», – дип торган район җитәкчесе булмаса, бәлки әлеге проектыбыз дәвамлы да булмас иде. Әмма Альберт Илгизәровичка рәхмәт, ул безнең һәр эшебезне хуплап, күтәреп ала. «Кичке уен», Сабантуйлар узгач, июнь урталарыннан июльгә кадәр авылларда үтә.

Аннары тирә-күрше авыллардан, регионнардан фольклор коллективларын чакырып, Кайбычның «Имәнлек» паркында гала концерт ясыйбыз. Безнең «Кичке уен» фестивалендә Югары Ослан, Буа, Апас, Тәтеш районнарыннан, Чувашия, Мари-Эл республикаларыннан коллективлар катнаша. Быел Чүпрәле, Буа, Әтнә районнарыннан, Казан шәһәреннән килделәр.



Кичке уенның иң матур күренеше – халыклар дуслыгы дип саныйм. Бәйрәм сценарие нәкъ менә төрле милләт вәкилләренең бердәмлеген күрсәтүгә басым ясап төзелә. Чөнки толерантлык, ягъни башка милләт кешеләренә хөрмәт белән карау хәзерге чорның иң мөһим мәсьәләләренең берсе, – ди Рамилә Рузалитовна.

Быелгы бәйрәмдә дә старт бирү урыны – Галия Кайбицкая исемендәге музей янынннан татарлар фольклор ансамбльләре кузгалып китте. Аларны авылның үзәгендә, җырлап-биеп, рус милләтендәгеләр каршы алды. Бераз баргач, аларга чувашлар, аннары керәшеннәр килеп кушылды. Район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин да алар арасында. Әнә шулай, уйнап-көлеп, «Имәнлек» паркына килеп җиттеләр. Ә анда бу ансамбльләрнең килүен стадионны тутырып халык көтеп тора иде.

«Кичке уен»да Әтнә районыннан «Алчәчәк» балалар бию коллективы, «Сөмбел» халык фольклор ансамбле солисткасы Гөлүзә Сираҗиева, «РамДан» гармунчылар дуэты, Чүпрәледән «Хелхем» чуваш фольклор ансамбле, Буа районының Күл Черкене авылыннан «Өммегөлсем» халык фольклор коллективы, Казан шәһәренең «Верес» ансамбле, Түбән Кама шәһәрендә яшәүче якташыбыз Миләүшә Гафурова-Ибраһимова, Кайбычның фольклор, вокал коллективлары, гармунчылары, «Ак калфак»лыларны үз эченә алган «Кайбыч кызлары» ансамбле катнашты. Исеме еракларга таралган үзебезнең «Авыл денс» халык балалар бию коллективы да өздерде генә.

«Кичке уен» җыр-бию, уен-көлке, уеннар белән үрелеп барды, балалар өчен аттракционнар эшләде.

## БУ – БЕЗНЕҢ УРТАК БӘЙРӘМЕБЕЗ

Татарстанда һәм башка төбәкләрдә этномәдәни кыйммәтләрне һәм гореф-гадәтләрне, туган телебезне саклау, халык уеннарын барлау, буыннар арасындагы элемтәне ныгыту, фольклор коллективлар белән иҗади хезмәттәшлекне киңәйтү максатындагы фестивальгә быел «Кайбыч таңнары» газетасы да кушылды.

Редакциянең дә «Кичке уен» фестиваленә үз өлешен кертүе очраклы гына түгел. Мәдәният хезмәткәрләре дә, журналистлар да төрле конфессия вәкилләренең борынгыдан килүче гореф-гадәтләрен, туган телләрен, мәдәниятен саклауга үзенең саллы өлешен кертә. Без бу хакта даими язабыз, республикада үткәрелгән



бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр яулыйбыз. Быел уңышыбыз тагын да саллырак – «Татмедиа» агентлыгы, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе, ТР Журналистлар берлеге үткәргән конкурста катнашып проект якладык һәм грант оттык. Бу конкурс югарыда телгә алган рухи кыйммәтләрне, этникара, конфессияара мөнәсәбәтләрне тормышка ашыру максатында игълан ителде. Фестивальдә, грант акчасының бер өлешен файдаланып, Олы Кайбычтан «Ак җилкән» халык театр коллективы, Олы Подберезьедан «Березка», Иске Тәрбиттән «Сәүдияр», Кече Мәмедән «Палан» халык фольклор коллективлары, Борындыктан «Якты йолдызлар», Каргалыдан «Сударыня» фольклор ансамбльләре, Колаңгыдан



«Радуга» вокал коллективларын бүләкләдек. Беренчедән, мәдәниятебезне үстерүгә үзләреннән саллы өлеш кертәләр, икенчедән, коллективтагыларның барысы да диярлек «Кайбыч таңнары»на язылган, газетабызның тугры дуслары. Руслар, татарлар, чувашлар, керәшеннәрнең милли мәдәниятен энҗе бөртегедәй саклаучы, аны киләчәккә илтүче бу фольклор коллективлар югалып баручы җырларны эзләп табып халыкка чыгара, төрле бәйрәмнәрдә, республика, ил күләмендә үткәрелүче чараларда җыр-биюгә осталыкларын күрсәтеп кайта, бердәмлеккә, дуслыкка дан җырлый.

**Луиза СӨНГАТУЛЛИНА,**
журналист, «Кайбыч таңнары»
газетасы баш мөхәррире

Ләйсән Саттарова фоторәсемнәре



# «КАРУРМАН: ЯЗЫЛМАГАН ДАСТАН» *пьесасы һәм спектакле мисалында милли эпосның заманча чагылышы*

*Луиза ШАРОВА,*
*филология фәннәре кандидаты,*
*Габдулла Кариев исемендәге*
*Казан татар дәүләт яшь тамашачы*
*театры директоры*



**Миф һәм эпос бездән – уйлый, иҗат итә һәм аны яңарта белгән кешеләрдән башка – бары тик үле фактура гына, алар бары тик артефактлар буларак кына кызыксыну тудыра ала.**

Бүгенге заман кешесе беренче тапкыр эпос белән кайда очраша? Әйтик, «Идегәй» дастаны һәр татар баласына да ана сөте белән сеңә алмый, бүгенге балалар кышкы озын кичләрдә «Кыйссаи Йосыф»ны да тыңлап үсми. Без инде халык традицияләре белән борынгыдан килгән ритуаллар дөньясында – авылларда да яшәмибез, димәк, каһарманнар дәверенә тоташтыра торган җепләр өзелгән диярлек. Гәрчә әле без үскәндә дә Таһир-Зөһрә, Кузы Көрпәч белән Баян-сылу, Түләк белән Сусылуның кем икәнен белә идек. Миф һәм эпос аша безгә үз кавемебезнең әхлакый-эстетик кодексы да сеңдерелгән...

Шулай бер Бродскийдан: «Нигә бүген эпос юк?» – дип сорагач, ул: «Язучының да, укучының да аңа вакыты юк. Көчебез дә җитми!» – дип җавап бирә. Нигә әле безгә үз дастаныбызны тудырып карамаска дип уйлаштык без Резеда Гарипова белән. Әйе, бу үзенә күрә Джордж Мартин, Дэн Брауннар рухындагы авантюра иде: татар мифопоэтик дөньясының бик популяр бер героен алып, аның хтоник үзәгенә – төшенә кадәр барып җитәсебез, тарихын яңадан язып карыйсыбыз килде. Экранизация аша үтеп керү, фэнтези, триллер яки детективка төреп бирү – бүгенге укучы/тамашачыга барып җитүнең уңайлы алымы. Гасыр буе кулланылган алым: Густав Майринк, Умберто Эко, Милорад Павич, Чыңгыз Айтматов, Фазил Искәндәр һәм башкалар без белгән танылган авторлар шушы хәйләкәр адымга барган. Исемлекне озак дәвам итеп булыр иде...

«Карурман» белән безгә тоташтырып булмаганны тоташтырып карау кызык иде, чөнки фэнтези – тамашачыны куркытмый торган форма, ул аны мавыктыра ала. Тамашачы интриганы тоя, үзен «экшн» белән җәлеп итәргә тырышуларын аңлый. Эпик форма – үзе үк экшн. Шул экшнны дөрес итеп төреп бирә белергә генә кирәк.


Милли эпос буенча бүгенге тамашачыны кызыксындыра торган тулы бер сәнгати дөнья төзергә була. Киноиндустрия, сериал буларак та яхшы барыр иде ул. Жанр синтезы төрлечә була ала – фэнтези, марвел стилендәге комикслар, анимэ, триллер, «Карнивал роу» кебек стимп панк дөньялар һәм башкалар. Бары тик эстетик яктан матур итеп һәм сак, үзебезнең тоемлау белән эшләнсен генә.

«Язылмаган дастан» жанрын сайлавыбыз белән без тамашачыга да сайлау мөмкинлеге бирәбез – ул теләсә тарихка ышана, теләмәсә – ышанмый, «Кем мин?» дигән сорауга теләсә җавап эзли, теләмәсә – җавап бирми. Кагыйдәләр анык һәм ихлас. Әмма шулай да без гомумтөрки катлам һәм контекстның, нарративлар белән парадигманың «Карурман» файдасына эшләвенә һәм генетик хәтерне уята алуына ышандык.

Яшь тамашачыга архаик тел катламының бар гүзәллеген җиткерү әһәмиятле иде. Безгә спектакльдә кулланыла торган сүзләр һәм мәдәни кодлар аңлатылган глоссарий булышты. Гарәп-фарсы алынмалары булмаган борынгы тел катламы белән эшләве җиңел түгел, ул мөмкин дә түгел, чөнки без инде аны кулланмыйбыз. Әле бит безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән шул заманнардагы дөньяга карашны реконструкцияләргә дә кирәк иде. Тел ул – дөнья моделенең көзгесе. Бу – бердәм Тәңре тотып торган, без инде җуйган кануннар буенча яши торган үзгә, гаҗәеп дөнья.

Пьесага алып керә торган ачкыч борынгы төркиләрнең тарихи ядкәре булган Күлтәгин язмаларыннан алынды: «Өстә – зәңгәр күк, аста көрән җир кылынганда, ике арада кеше углы барлыкка килде».

Спектакльдә Елъязмачы һәм сакраль дөньяларны тоташтыручы образы итеп Бөек Каһин алынган. Әлеге рольгә без экспериментлардан курыкмый торган җырчы Зәринә Вилдановны чакырдык.



**«Кыйссаи Йосыф». Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме**

Спектакль өчен пьесаны бик кысарга туры килде. Шунлыктан күп нәрсә «кадр артында» калды. Шуңа да бу тарихны сериал форматында эшләп булыр иде дигән ымсыну кала бирә, күңелдә йөри. Әгәр безгә андый тәкъдим булса, бик теләп алыныр идек. Сериал һәм хәтта геймер форматы бик актуаль, ул фантазиягә урын калдыра.


Халык эпосларында мәдәни традицияләрнең тотрыклы элементлары теркәлгән, халыкның менталитеты ачык чагыла. Драматург һәм режиссёрның эпик материалга мөрәҗәгате үз халкының милли мәдәниятенә тирән үтеп керергә, гомуммилли кыйммәтләрне торгызырга һәм баетырга мөмкинлек бирә. Бүген милли театрларның үсеш перспективалары турында сүз барганда чыганакларга һәм тамырларга мөнәсәбәт мәсьәләсе ачык кала. XX гасыр тарихы милли үзаңнан эпосларны юк итәргә тырышкан кискен, драматик мизгелләрне дә бик яхшы хәтерли. Кайбер халык шедеврларының театраль язмышы да драматик иде: алар халык мәхәббәтен казану белән беррәттән, партия принциплары буенча тәнкыйтьләнде дә, бу әсәрләр нигезендә куелган спектакльләр йә сәхнәдән төшерелде, яки менеп тә җитә алмады. Халык эпослары белән театр мөнәсәбәтләренең катлаулы язмышы аларның милли театр үсеше өчен гаять зур роль уйнаганын раслый. Болды андый чорлар – театр нәкъ шундый әсәрләр нигезендә куелган спектакльләре белән милли рухи кыйммәтләрне җиткерүче төп канал булып калды.

Без саха халкының театрын искә төшерсәк, драма театры турында гына түгел, ә чын мәгънәсендә Ритуал һәм Миф киңлегендә фикер йөртүебезне аңлыйбыз. Тойукның ниндидер бер әфсен кебек шаманнар, Рухлар дөньясы белән тоташтыручы булуын тән тиребез һәм җан сулышыбыз белән тоемлыйбыз.

Ни кызганыч, без үзебезнең аутентика белән элемтәне югалтканбыз һәм күп юнәлешләрдә кармаланып кына атлыйбыз. Ә инде эзләнүдән, табудан һәм бу юнәлештәге милли дә, заманча да экспериментлардан һәм чикләрне киңәйтүдән курыксак, үзебезне «театр-музейга» бикләп куеп, этнографик форматта гына да кала алабыз. Мин театрда аутентик башлангыч белән драматик гәүдәләнешнең үтемле, кабатланмас формаларын табып, яңа сүз әйтә алуга чыгуыбызны теләп идем...

## Тәкъдимнәр

**2.** Мәдәният учреждениеләре һәм шәхси затлар өчен милли эпос буенча оригиналь һәм креатив иҗади проектлар (театрлар өчен пьеса һәм инсценировкалар, фильмнар һәм сериаллар өчен сценарийлар, виртуаль уеннар өчен сценарийлар һәм аларны иҗади яктан эшкәртү) булдыру мөмкинлеге өчен гонорар фонды булган махсус программа кирәк.




**1.** Милли эпос белән академик корпуста да, иҗади яктан да эшли ала торган милли кадрларны (филологлар, ягъни фәнни хезмәткәрләр, драматурглар, сценаристлар, тәрҗемәчеләр һәм башкаларны) әзерләргә – аларны эшкә урнаштыру перспективасы белән түләүсез укытырга кирәк. Бәлки, бу үзебезнең һәм халыкара экспертлар җәлеп ителгән махсус курс булыр. Бу проблема бар, эпос өлкәсендә фәнни консультация өчен белгеч табуы да шактый кыен, ә белемне яшь буынга күчереп өлгермәсәк, буыннар алмашы бөтенләй өзеләчәк.

**3.** Милли эпос буенча сыйфатлы реклама контенты әзерләү һәм аны шәһәр киңлегенә һәм ТВга кертү. Кешеләр үз геройлары һәм сюжетлар белән горурланырга өйрәнергә тиеш. Әмма бу бәйләнеп-туйдыру юлы белән түгел, акрынлап кызыксындыру юлы белән барырга тиеш.


**4.** Акчалата бүләкләү каралган Милли эпос укучылар фестивале оештыру.

**5.** Милли эпос буенча акчалата бүләкләү каралган Театр фестивале оештыру.

**6.** Милли эпос мирасы буенча музыкаль лаборатория һәм музыкаль фестиваль оештыру.

**7.** Милли эпос инсценировкасы буенча семинар һәм лаборатория оештыру. Ул бәйге нигезендә дә була ала – иң яхшыларын сайлап алып, аларны Татарстан театрлары куя ала.

**8.** Татарстан һәм татар диаспорасы яшәгән өлкәләрдә өйрәнү өчен Милли эпик мирасны цифрлаштыру һәм популярлаштыру. Бу шулай ук милли контент куела торган платформалар өчен дә актуаль, кешеләр (бигрәк тә мәдәни өлкәдә эшләүчеләр, мөгаллимнәр) аны эзләп табарга, кулланырга теләячәк.




**(Быелның 2-14 август көннәрендә «Тормыш стиле – мәдәни код» II халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать этно-fashion фестивале кысаларында узган «Заманча мәдәниятнең эпик константасы: милли эposларны саклау һәм популярлаштыру проблемалары» Халыкара конференциясеннән чыгыш)**

# МӨСЛИМЛЕЛӘРДӘН – *халкыбыз хәзинәсенә рухи мирас*

***Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,***
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык*
*иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*



**Мөслим районы Яңа Карамалы авылында информантлар белән очрашу. 2017 ел**

**Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен торгызу белән шөгыльләнүче галимнәр гомер-гомергә кыр тикшеренүләренә мөрәҗәгать итә киләләр. Милләт тарихын бербөтен итеп күзаллауда фәнни экспедицияләрнең ярдәме зур. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан сигез дистә елдан бирле уздырыла торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.**

Мөслим туфрагы – борынгы һәм бай тарихлы, биредә мең еллар дәвамында татарларның ата-бабалары матди һәм рухи байлыклар тудырып гомер итәләр. Гасырлар дәвамында барган төрле вакыйгаларга бәйле үзгәрешләр кичерүгә карамастан, биредә төпләнеп яшәгән нәселнең теле, дине, мәдәни хәзинәләре буыннан буынга сакланып килә. Тамырлары татар булган, татар мәдәниятле халык булып ныгып формалашкан, бүгенге көндә дә сөйләшендә, гореф-гадәт һәм йолаларында, җырларында, көйләрендә, мәзәкләрендә, төрле язмаларда, шөгылендә-гамәлендә, уйларында-фикерләвендә татарлыкны алга куйган Мөслим районы һәм аның кешеләре татарларны һәрьяклап өйрәнә торган Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өчен гаять кызыклы. 2017 елның җәендә комплекслы фәнни экспедицияләрнең берсе нәкъ менә бирегә оештырылган булу бер дә гаҗәп түгел. Экспедициябезнең төп максаты – татарларның мөслимлеләргә хас рухи байлыгын барлау, теркәү, моңа кадәргесе белән чагыштырып өйрәнү.

Бүгенге көндә Мөслим районында яшәүче 23 меңгә якын кешенең 90 процентка якынын татарлар тәшкил итүе мәгълүм. Мөслим районы татар авылларында моңа кадәр алып барылган кыр тикшеренүләренә инде илле елдан артык вакыт үткән. Телебезне, татарлыгыбызны саклау проблемалары янәдән кискенләшкән бер дәвердә тугандаш ике республика чигенә урнашкан Мөслим районы милли-мәдәни мирасын кабаттан барлап, яңа эзләнүләр алып бару көн кадагындагы мәсьәлә булуы аңлашыла. Милли мирасыбызны – татарларның милли-мәдәни, рухи тормышын, тел үсеше-үзгәрешләрен, сәнгатьтәге алгарышын ачык күзаллау һәм, әлбәттә, алга таба саклау өчен халкыбызның шушы төбәктәге вәкилләре белән очрашып, аралашып, үзара фикерләшеп яшәү, чыннан да, гаять зарур. Галимнәрнең халыкка якынлыгы бәхәсле мәсьәләләрне хәл итүдә объективлыкка китерә, уңай нәтиҗәләр бирә ала. Мөслимгә үткәрелгән экспедиция «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» программасы нигезендә уздырылды.

Экспедиция төркемендә халыкның тел-авыз иҗатын, төбәк сөйләшен, декоратив-гамәли сәнгатен, халык һөнәрләрен, музыкасын өйрәнүчеләр, борынгы кул эшләнмәләре, кием-салым бизәлеше белән кызыксынучы, кабер ташъязмаларын укып тикшерүче, гарәп язулы китаплар һәм кулъязмаларны туплаучылар бар иде. Һәркем үз юнәлеше буенча материал туплады, халык белән аралашты. Мөслим авылларында язып алынган диалектологик материаллар, сәнгать, музыка, археография, эпитафика өлкәләренә караган үрнәкләр, фольклор әсәрләре – татар халкының бүгенге торышына, халкыбыз яшәешенә, аның бүгенге сулышына тере мисал.

Фольклорчы буларак, минем үземне иң кызыксындырганы – бу төбәкнең авыз-тел иҗаты. Бу як кешеләре фольклорны теркәп һәм теркәтеп калдыруга элек-электән зур өлеш керткәннәр. XX йөзнең 40нчы елларыннан алып татар халык иҗатының кайсы гына жанры буенча нинди генә җыентык чыкса да, аларда Мөслим районы кешеләреннән язып алынган яисә аларда саклана



**Тәйгелдедән Рәфкать ага Кәримовлар гаиләсендә**

торган язмалардан күчерелгән фольклор әсәрләрен, я булмаса алардан язып алынган вариантлар турында мәгълүматларны очратасың. Хәмит ага Ярми җитәкчелегендә Минзәлә, ул вакыттагы Калинин, Мөслим, Актаныш районнары авылларын иңләгән 1948 елгы экспедициядә, мәсәлән, фольклорчы Халидә Гатина, институт хезмәткәре Шәмсезәйнәп Максудова, КДУ студенты Н. Фәттахов катнашкан. Ул чорда институтыбыз галимнәре бу яклардан шактый зур багаж белән кайтканнар. Мөслим районы Ташлыяр авылында атаклы әкиятче Зариф Мөэминов (1893-1966), Әмәкәй авылында Шәфыйк Хөснуллиннан Х. Ярми үзе һәм Х. Гатина озын-озын әкиятләр язып алганнар. Үткән гасырда бу яклардан туплап алып кайтылган материаллар, барысы да бик пөхтәләп Мирасханәгә – институтның архив фондларына тапшырылганнар. Алай гына да түгел, ул чактагы экспедицияләрдә халыктан җыелган фольклор үрнәкләре бик күп җыентыкларга кертелгән, шул исәптән 1989 елда Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булган 12 томлык академик «Татар халык иҗаты» җыентыгы томнарында лаеклы үз урынын тапканнар яисә теге я бу фольклор әсәренең варианты буларак күрсәтелгәннәр.

Татарстанның иң-иң татар төбәкләреннән саналган Мөслим ягы бүгенге көндә нинди рухи хәзинәләр саклый? Талантлы татар ул-кызларын күпләп биргән, элекке елларда галимнәр һәм язучыларга менә дигән фольклор истәлекләре тапшыра алган әңгәмәдәшләр яшәгән төбәккә барыр алдыннан ук өметем зурдан булып, баскычның да иң югарысын әзерләдем, ник дигәндә, милләтебезне милләт иткән вәкилләр – татар телле чып-чын татарлар, чыннан да, шушында яши бит инде! Татарстанның көнчыгышына, Ык елгасы буена урнашкан Мөслим районы авыллары – татарлыкның нәкъ каймагы, шуңа да бирелдә материалның күпләп табылачагына һич шигем булмады. Чыннан да, Мөслим районы авылларында аралашкан әңгәмәдәшләрем өметләремне тулысы белән акладылар. Авылларда татар фольклоры – халкыбызның тутыкмас сүз сәнгате – гөрләтеп яши! Бер атна вакыт эчендә Мөслимнең өч дистә диярлек авылында булдык. Информантлар арасында Тәйгелдедән Рәфкать ага Кәримов кебек менә дигән әкият сөйләүче, тарихи җыр сүзләрен әйтеп бирүче кешеләргә кадәр очрады, ә бу инде – бүгенге заманда фольклорчы өчен әйтеп бетергесез табыш. Әмәкәйдән Бания апа Борһанова, Исәнсефтән Зәйтүнә апа

Исмәгыйлева кебек, үзенең җор теле белән игътибарны җәлеп итүче, хәтта гап-гади соравыңа җавапны шигырь белән әйтеп бирү сәләтенә ия тел осталарының күплеге белән таң калдырды Мөслим ягы.

Борынгыдан килгән йолаларыбыз, гореф-гадәтләр инде онытыла, юкка чыга бара дип чаң суккан бер вакытта халкыбызның хәтерендә, өлкән буын кешеләренең телендә бик күп кыйммәтле истәлекләр, тел һәм рухи байлыгыбыз саклана әле. Авыз-тел иҗатында халыкның холык чалымнары, тел байлыгы, теләк-омтылышлары, хис-кичерешләре, нәрсә уйлап борчылуы, ни өчен шатлануы, нәрсәләрне тәнкыйтьләве чагыла.

Мөслим районы авылларына – Иске Вәрәш, Вәрәшбаш, Катмыш, Мәлләтамак, Тегермәнлек, Тугаш, Югары Табын, Түбән Табын, Олы Чакмак, Шуганка, Баланлы, Төйгелде, Метрәй, Салауз Мухан, Яңа Усы, Каенсаз, Татар Шураны, Краснояр, Баек, Иске Карамалы, Яңа Карамалы, Әмәкәй, Исәнсеф, Үрәзмәт, Симәк һәм район үзәге булган Мөслим авылының үзенә ясалган сәфәр вакытында мөслимле милләттәшләребездән язып алынган сөйләмә фольклор материалларында – татар рухы. Үзебез тарафыннан информантлардан язып алынган кайбер истәлекләрне укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

## ТЫЮЛАР

*(халык педагогикасы, тыю жанры)*

Көйгән ипи ашасаң, бүредән курыкмассың.
Кырмысканы үтермә, әниеңнең күкрәге шешәр.
Үзеңнән түбәнгә (кечкенәләргә) сукма, кулың корыр.
Иягеңә таянма, әниең үләр.
Капкадан чыкканда сул аягың белән атлап чыксаң, эшең уңмас.
Орчыкны матур урасаң, киявең матур була.
Кабаның артына карап утырсаң, бианаң каба төбе белән кыйный.
Алъяпкычыңның тискәре ягын бәйләсәң, кешегә тискәре күренерсең.
Зиратка бармагың белән төртергә ярамый, бармагың шешә.
Сишәмбе көнне кер юарга ярамый, кайгы теләү була.
Җомга турында эш эшләргә ярамый, эшең ут булып янар.
Аягыңны селкеп утырма, шайтан килер.
Бисмилласыз ашый башласаң, ризыгыңны шайтан ашап торыр.
Аягыңа озак киенсәң, ярлы булырсың.
Иләк аша карасаң, киявең кылый булыр.
Кәлтә койрыгын өзсәң, башың кайгыга батар.
Ут белән уйнасаң, төнлә «балык тотарсың».
Күп сөйләшмә, телеңә тилчә чыгар.
Сыныгыңны ашап бетер, бәхетең шул сыныкта калыр.
Бәрәңге тукмагын ялама, киявеңнең башы таз булыр.
Зират әйберсенә тимә, мәетләр ачуланыр.
Җиргә төкермә, авыз кырың чабырыр.
Ачык урынга олы йомышыңны үтәмә, кояшны рәнҗетерсең.
Олылар сөйләгәндә катышма, телең үсеп, авызыңа сыймый башлар.
Ипи валчыгын койма, хәерче булырсың.
Тәрәз төбенә ризык куйма, агуга әйләнер.
Көянтәне атлап чыкма, кыярак (төер, биз) чыгар.

**Тәскирә Газетдин кызы НИЗАМИЕВА (1943 елгы),**
**Вәрәшбаш авылы**



**Бәһиҗә Сәрвәретдин кызы Бәһаува**

## СИХЕР ТУРЫНДА

Сихер – бозым ул, куркыныч нәрсә. Кеше килә чирләп торам дип, килеп җиткәнче үк төшемә керә. Сихер эләккән булса килгән кешегә, белеп торам кем сихере икәнен, дәвасын да беләм. Минә бервакыт берәү килде, ире өеннән чыгып киткән моның. Алдан ук күргән идем төшемдә: бер кыз бала аш бүлә кешеләргә. Димәк, бозым ризык аша кергән. Моның ире дә ашады бу кызның бүлгән ашын, ашап бетерә алмады. Ир кире кайтачак, әмма тиз кайтмый дип юрадым. Сихерне чыгару җае – төштәге дога белән. Шул доганы укып өшкерергә кирәк. Кеше терелә, киткән ир кайта. Әйтмим нинди дога, ярамый әйтергә.

**Бәһиҗә Сәрвәретдин кызы БАҺАУВА (1940 елгы), Иске Вәрәш авылы**

## ЧУМА ҮРДӘК
*(җырлы уен)*

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата, ярата,
Гөлфия үзенә иптәш эзли,
Белмим кемне ярата, ярата.

Парлылар арасыннан берсен ияртеп китә дә, артка барып басалар. Артыннан, кемне сайласа, шуның исемен әйтеп:

«Ул фәләнне ярата, ярата», – дип калалар. Уен дәвам итә.

«Ал да кирәк, гөл дә кирәк», «Әби, күмер бир әле» кебек уеннар да уйнала.

Ботка пешкәч, җиргә түгәрәк ясап утырышып, ботка ашыйлар. Каргаларга да өлеш чыга боткадан.

– Илләр имин булсын! Көннәр тыныч булсын! Каргаларыбызны алдагы елда да сыйларга насыйп ит! – дип теләкләр әйтелә. Аннан бәйрәм концерт номерлары белән дәвам итә. Бәйрәмгә авыл халкы да килә. Ботка бөтен кешегә җитә, әле әби-бабайларга күчтәнәчкә дә кала.

**Флера Рифкать кызы МӘХҮБРАХМАНОВА (1970 елгы), Тугаш авылы**

## МӘЛЛӘТАМАК
*(топонимик риваять)*

Мәллә – елга. Ул Ыкка коя. Төшкән урыны «тамак» дип атала. Шул тамакка урнашканга, авылның исеме – Мәлләтамак. Мәлләтамак элек Тамьян тавы янында булган. Су баскач, хәзерге урынга күчергәннәр. Мәллә нәрсәне аңлата – белмим. Шушында беренче килеп утырган кешенең исеме түгел микән.

**Игорь Акмал улы ӘХМӘТШИН (1939 елгы), Мәлләтамак авылы**

## КОЛХОЗ ТҮГӘРӘГЕ
*(уен)*

Яшьләр клубта култыклашып әйләнә торган иде. «Колхоз түгәрәге» ди идек шуны. Җырлап әйләнә идек:

Байкал күле, Байкал күле,
Байкал күле балыклы,
Рәхмәт яусын Ысталинга,
Бәхетле итте халыкны. –

Шулай дип җырлый торган идек, үзебез бәхетле булмасак та. Бәхетсез дә түгел идек, рәхәт чаклар иде.

Уен түгәрәгенә бер кешене чыгаралар. Аңа атап җыр җырлана:

Ысталин зур урында,
Ысталин зур урында,
Рапорт бирергә килмәдем
Сөюләрем турында.
Тагын болай да җырлый идек:
Их, кызлары нинди нәфис,
Арта бара кайнар хис,
Кайнар хисле яшь кызлардай
Яшь егетләр дә бар ич.
Әй, минем кырчы дустым,
Арышлар ару уңсын,
Күрәеп үссен бодайлар,
Солылар сылу торсын.
Уртада – кырчы дустым,
Бодайлар ару уңсын,
Көләч йөзле көнбагышлар
Башларын горур борсын!

**Рәзифә Хантимер кызы ФӘТТАХОВА (1935 елгы),**
**Катмыш авылы**

## САМАВЫРНЫ ҖЫККАНЧЫ ЭЧ!
*(Кунак хөрмәтләү)*

Самавырны җыгып эчә башлагач та җиде чынаяк чәе кала, ди торган иде әби. Самавырның борынына кадәр суы үзе ага, борынына җиткәч, суы аксын өчен, авыштырырга кирәк, шул җыгып эчү була. Самавырны җыкканчы да эчмәдегез бит әле, кая кузгаласыз?!

**Миләүшә Ранас кызы Гәрәева (1961 елгы),**
**Иске Карамалы авылы**

## МӨНӘҖӘТ

Раббым Аллам, диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса,
Атаң-анаң разый булса.

Раббым Аллам, диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса
Күршеләрең разый булса.

Раббым Аллам, диде Муса
Миңа җәннәт булыр микән?
Сиңа җәннәт булыр, Муса
Кыз туганың разый булса.

**Халисә Дәүләтгәрәй кызы Гәрәева (1953 елгы),**
**Баек авылы**

## АУЛАК ӨЙДӘ ЙӨЗЕК САЛЫШ УЕНЫ
*(йола фольклоры)*

Берәрсенең әти-әниләре кунакка киткәнен белсәк, аулак өй ясый идек. Хуҗа кыз бәлеш сала. Кыз, җегет – бар да керә.

Төрле уеннар уйный торган идек. Йөзек салыш. Парлап бастыралар. Аркага арка. Бер, ике, өч дип санныйлар. Өч дигәндә икең дә башын бора, кем кайсы якка борасы килә, шул якка. Шул вакытта бер-береңә карасаң, бу ике кешене йолдыз санарга чыгаралар. Җәзасы шул була.

**Венера Мияссәр кызы Нургалиева (1970 елгы),**
**Үрәзмәт авылы**

**Экспедиция материалларының дәвамын журналыбызның 4 нче (2022 ел) санынннан укый аласыз.**

# ЧАБАКСАР. ФОЛЬКЛОРИАДА. «ӘЛЛҮКИ»

**Татарстаннан татар кызы Миләүшә Закирова Габдулла Тукай шигыренә язылган «Әллүки» татар халык җыры белән I Бөтенроссия балалар фольклориадасында катнашты. Фольклориада июнь аенда Чувашия Республикасы башкаласы Чабаксар шәһәрендә үтте. Бирегә Россиянең 76 регионыннан меңнән артык яшь катнашучы – фольклор, хореография, җыр һәм инструменталь ансамбльләр җыелган иде.**










«БЕЗ ЧАБАКСАРДА ДҮРТ КӨН БУЛДЫК. БИРЕДӘ ТӨРЛЕ ХАЛЫКЛАРНЫҢ МӘДӘНИЯТЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫК. ТАТАРСТАН ФЛАГЫ АСТЫНДА МАСШТАБЛЫ ЙӨРЕШТӘ КАТНАШКАНДА ШУЛКАДӘР ЗУР ГОРУРЛЫК ХИСЕ ТОЙДЫМ, ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ МИН – ОЛИМПИЯ УЕННАРЫНДА! МИН БАШКАРГАН ТАТАР ҖЫРЫ ТЫҢЛАУЧЫЛАРНЫҢ КҮҢЕЛЕНӘ ҮТЕП КЕРДЕ – МОНЫСЫ ДА ЗУР ГОРУРЛЫК», – ДИ МИЛӘҮШӘ.




Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

Балалар фольклориадасы – Россия халыкларының традицияләре белән таныштыру өчен илнең төрле якларыннан уртак мәйданга җыелган балалар һәм яшьләр иҗат коллективлары чыгышлары. Әлеге зур масштаблы фольклор фестивале Россия халыкларының мәдәни мирасы елы программасына кергән.

Шул ук көннәрдә – Фольклориада алдыннан Чабаксарның Кызыл мәйданында XXX Бөтенроссия «Родники России» халык иҗаты фестивале ачылды. Россиянең унлап регионыннан килгән иҗат коллективлары арасында Казаннан «Бәхетле балачак» хореография ансамбле дә бар иде.

# Уңыш

Әхмәт Ерикәй сүзләре,
Наилә Яхина көе

Әхмәт Ерикәй сүзләре

Наилә Яхина музыкасы




Үсеп утыра арыш,
Һәр башагы бер карыш.
Бодай үсә ургылып,
Дулкынланып, зур булып.

Әгәр күрсәң солысын –
Исең китеп торырсың.
Әнә кара тарыга,
Үрмәли югарыга.

Зәңгәр чәчәкле җитен –
Читләтеп үтү читен.
Киндер бигрәк тә уңган,
Әйтерсең кара урман.

Кәбестәләр, суганнар
Түтәлләргә тулганнар.
Кишер белән чөгендер –
Тик җыеп кына өлгер.

# «ЧӘК-ЧӘК» бәйрәме

(МӘКТӘПКӘ ХӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН)

*Розалия ШӘЙДУЛЛИНА,*
*Арча, «Үрнәк» балалар бакчасы музыка җитәкчесе*

*(Залның ике ягында ике өй, өйләр алдында эскәмияләр тора. Бер яктан кызлар, икенче яктан малайлар чыгып, татар биюе башкара.)*

**Илзирә:** Дуслар, бүген нинди матур, җылы көн!
**Камилла:** Кояш нурларын кызганмый!
**Әмир:** Кызлар, малайлар! Сизәсезме? Нинди тәмле исләр?
**Рания:** Әйе, Айсылу апа нидер пешерә...

*(Балалар бер өйнең тәрәзәсенә килеп карый.)*

**Айзат:** Эх, ашыйсы килә башлады! Алсу апа өеннән дә тәмле исләр килә.

*(Балалар икенче өйнең дә тәрәзәсеннән барып карый. Өйләрдән апалар чәк-чәк алып чыга.)*

**Апалар:** Исәнмесез, балалар!
**Балалар:** Исәнмесез!
**Айсылу апа:** Балалар, бүген нинди көн икәнен беләсезме?





**Балалар:** Юк.

**Айсылу апа:** Бүген Чәк-чәк көне. Шуңа сезгә чәк-чәк пешердек.

**Алсу апа:** Балалар, әйдәгез бүген «Чәк-чәк» бәйрәме уздырабыз.

*(Чәк-чәкне өстәлгә куеп, эскәмиягә барып утыралар.)*

**Илзирә:**
Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына – чәк-чәк.

**Рания:**
Бавырсак һәм кош теле,
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш,
Бар кыстыбый һәм бәлеш!

**Алсу апа:** Барлык бәйрәмнәр арасындагы иң татлы, иң баллы, иң тәмле бәйрәм.

**Айсылу апа.** Чәк-чәк – татар халкының визит карточкасы. Россиянең башка шәһәрләрендә, чит илләрдә белем алучы яшьләребездән дус-ишләре күчтәнәчкә чәк-чәк алып килергә сорый икән, димәк, без генә түгел, бар җиһан әлеге ризыкны үз итә. Тарихи чыганакларга күз салсак, татар халкы элек-электән умартачылык белән шөгыльләнгән. Шуңа да бал кушылган шундый татлы чәй ризыгы уйлап тапкан. Аны бары тик кунак килгәндә генә пешергәннәр. Аеруча туй өстәлендә популяр булган.

**Руфина:**
Чәк-чәк атлы тәмле ризык
Өстәлләрне бизәгән.
Шуңа күрә безнең халык
Өстәленнән өзмәгән.

**Айсылу апа:** Туйларны, төрле бәйрәмнәрне чәк-чәктән башка күз алдына китереп тә булмый.



**Айзат:**
Телеңне йотарлык чәк-чәк
Һәр бәйрәм табынында.
Баллы-татлы бу ризыкны
Ярата барчабыз да.
**Әмир:**
Һичкем аны табынына
Күрсәтергә куймаган.
Халкым яраткан кунагын
Чәк-чәк белән сыйлаган.

*(«Чәй эчәбез бергәләп» җыры башкарыла.)*

**Балалар:** Чәк-чәкне кем уйлап чыгарган?

**Алсу апа:** Риваять буенча, кайчандыр Болгар ханы үз балаларының туена моңарчы кеше татып карамаган тәм-том бүләк итәргә тели. «Җиңел әзерләнсен, озак саклансын һәм бәйрәм табынын бизәсен» дигән таләп куя. Шундый ризык табылса, ул Болгар ханлыгы символына әйләнер дип уйлый. Хан бик күп ризык татып карый, бары тик кетүче хатыны пешергән тәм-том гына аның таләпләренә һәм зәвыгына туры килә. Хатын аны бал, йомырка һәм оннан ясаган була. Ханга бу сый искиткеч тәмле булып тоела. Бүген дә табын күрке булган чәк-чәк безгә әнә шул заманнардан килеп җиткән.

Чәк-чәк – туганлык, бердәмлек символы. Чөнки гаилә әгъзалары һәм туганнар кебек, камырдан ясалган шарчыклар бал белән бер-берсенә яхшылап беркетелгән.

**Әмир:**
Әнкәй пешерде чәк-чәк,
Капкалыйм аны чак-чак,
Мин ашагачтын чәк-чәк,
Чәк-чәк тә кими чак-чак.
Баллы чәк-чәк! Тәмле чәк-чәк!
Кимесә шулай чәк-чәк,
Әбигә дә җитәчәк,
Бабайга да җитәчәк,
Тик кызганыч шунысы –
Барыбер, бер бетәчәк.

*(«Чәк-чәк пешерү» уены.)*

*(Өстәлдәге подноска сары төстәге киндер-сюрприз шарлары куела. Аларга ябыша торган тасмалар ябыштырылган. Балалар ике командага бүленеп, икенче өстәлдәге ике түгәрәк тәлинкәгә шарчыклардан «чәк-чәк»өяләр. Апала-*

*ры «чәк-чәк»ләренә карап, балаларның уңганлыгын, җитезлеген сыный.)*

**Апалар:** Ай-яй, нинди чәк-чәкләр килеп чыкты!

**Руфина:** Ни өчен ул «чәк-чәк» дип атала?

**Айсылу апа:** Кемдер чәк-чәкнең телне йотарлык тәмле булуына сылтый, кайберәүләр исемне камыр кисkәндә чыккан тавышка охшатып биргәннәр, ди. Янәсе, куна тактасы өстендә «биегән» пычак шундый тавыш чыгара, икән. Икенчеләре, чәк-чәкне авызны чәпелдәтми генә ашарга мөмкин түгел, шул чәпелдәү тавышыннан «чәп-чәп», аннан «чәк-чәк» килеп чыккан, ди.

**Алсу апа:** Әлегә исеменең килеп чыгу тарихы һәм төгәл мәгънәсе табылмаган. Борынгы болгарларда ислам кабул ителгәнче тәңречелек булган. Чәк-чәк шул вакытларда йола ризыгы буларак пәйда булырга мөмкин дигән фаразлар да бар.

**Алсу апа:** Балалар, карагыз әле, бүген нинди матур көн! Табигатьтән күз алырлык түгел. Көз – нинди матур ел фасылы!

*(«Яфрак» бәйрәме җыры башкарыла.)*

**Айсылу апа:** Без бәләкәй чакта, уйнаганда, үсә төшкәч кич утырганда, аулак өйләрдә табышмаклар, мәкальләр әйтешә идек. Шул уеннарның берсен – «Уклау уены»н сезнең белән дә уйнап алыйк әле.

*(Балалар паласка түгәрәк ясап утыра. Уклауның кызыл тасма бәйләнгән башы кемгә карый, шул бала мәкальнең башын әйтә, икенчесе дәвам итә.)*

– Тирләп эшләсәң – тәмләп ашарсың.
– Ипи, тоз – якты йөз.
– Дөньяда иң йомшак кул – әниләр кулы.
– Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.

**Алсу апа:** Бигрәк тапкыр балалар! Ә менә табышмаклар чишә беләсезме?

**Балалар:** Беләбез дә, яратабыз да!

*(Апалар табышмаклар әйтә.)*

Йомырка белән онны
Бутап, камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. *(Өчпочмак.)*



Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың,
Ул нәрсә? *(Коймак.)*


Камыр эчендә бәрәңге,
Йә, уйлап кара әле. *(Кыстыбый.)*

Иттән генә торам мин,
Майга чумып чыгам мин. *(Парамач.)*

Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп,
Аша, дустым, син шулай. *(Чәк-чәк.)*

**Азалия:**
Без биибез тыпыр-тыпыр,
Без биебез тып та тып.
Бер башласак, бик тиз генә
Булмый безне туктатып.

*(Татар халык биюе башкарыла.)*




**Карга әйтә: «Кар-кар!»: юаткычлар, мавыктыргычлар, әйтенүләр, санамышлар, такмазалар / [төз. А. Галиәхмәтова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 63 б.**

# Әти-әниләр колагына

**Балалар фольклоры баланы туган көненнән алып озата бара: һәр уен хәрәкәт, җырлар, такмаклар, такмазалар белән үрелеп, сабыйны нәрсәгәдер өйрәтә, тормышка әзерли, аңа сабак бирә. Әлеге китапта балалар фольклорының буыннан буынга тапшырыла килгән иң матур үрнәкләре бирелә. Аларны баланы уятканда, юындырганда, тәпи киткәндә, телен ачтырганда кулланырга мөмкин, үсә төшкәч, балаларның үзләренә дә өйрәтергә була.**

## ЮАТКЫЧЛАР

### УЯНАБЫЗ

*Тор, тор, тургай,*
*Таң, таң ата бугай.*
*Тургай, кил, чыпчык, чык,*
*Чырык, чырык, чырык!*
*Йә, сандугач, күзең ач,*
*Тәрәзәдән, тургай, кач!*
*Чырык, чырык тургай,*
*Тәрәзәмә кунмай,*
*Бер кечкенә кошым бар,*
*Алып чыгып булмай.*



### ҮС-ҮС ИТӘБЕЗ

*Казлар канат бирсен,*
*Торналар аяк бирсен,*
*Бүдәнәләр май бирсен,*
*Ябалаклар йон бирсен,*
*Балам зур үссен, үс-үс-үс!*
*Үс, улым, үс, үс, әйдә,*
*Дөнья бик киң – сыярсың,*
*Аягың җиргә терәрсең,*
*Башың күккә сузарсың.*
*Бу җирләргә сыймасаң,*
*Галәмнәргә чыгарсың,*
*Көчтәнәчләр апкайтып,*
*Әнкәеңне сыйларсың.*
*Сузылсын – су буе булсын,*
*Киерелсен – киртә буе булсын,*
*Бәхетле, тәүфыйклы булсын,*
*Ата-анасына шәфкатьле*
*булсын.*





## МАВЫКТЫРГЫЧЛАР

### КҮК-КҮ, ЧЫПЧЫК

*Күк-күү, чыпчык,*
*Тәрәзәдән очып чык,*
*Әминәнең өстенә*
*Матур күлмәк бирep чык!*
*Күк-кү, чыпчык,*
*Тәрәзәдән очып чык.*
*Илдусның башына бал сөртеп чык,*
*Галиянең башына май сөртеп чык.*
*Әлфиягә баллы кашык,*
*Майлы ботка бирep чык!*
*Күк-кү, чыпчык,*
*Минем матур апаема*
*Тәмле прәннек бирep чык.*

### СӨЙЛӘШЕРГӘ ӨЙРӘНӘБЕЗ

*Әт, әт-тә дип әйт,*
*Әтәч койрыгы бирем.*
*Ән, ән-нә дип әйт,*
*Әлбә бирем.*
*Ап, ап-апа дип әйт,*
*Ак алма бирем.*
*Әп, әп-әби дип әйт,*
*Әфлисун бирем,*
*Тешеңә йомшак булыр.*
*Чәп-чәп ит, бала, чәп-чәп ит,*
*Чәп-чәп иткәч үсеп кит,*
*Чәп-чәп ит тә йөреп кит,*
*Белгәнеңне сөйләп кит.*

## ЭНДӘШЛӘР

### ЯҢГЫР, ЯУ, ЯУ!

*Яңгыр, яу, яу, яу!*
*Иләктән, чиләктән,*
*Пәрәмәчтән, коймактан,*
*Арпадан, бодайдан,*
*Эшләр китәр уңайдан.*
*Яңгыр, яу, яу, яу,*
*Ашлык уңсын ызанда,*
*Ботка пешсен казанда;*
*Алтын кашык базарда,*
*Көмеш кашык болытта.*
*Нык яварга онытма!*

### КОЯШ, ЧЫК, ЧЫК!

*Майлы ботка бирермен.*
*Майлы ботка казанда,*
*Тәти кашык базарда.*
*Әти китте базарга,*
*Тәти кашык алырга.*
*Тәти кашык саф алтын,*
*Кирәкми безгә салкын!*
*Эт кояшы, ары кит,*
*Тәти кояш, бире кил!*
*Кояш, чык, чык,*
*Майлы ботка бирермен.*
*Әти китте базарга,*
*Тәти кашык алырга.*
*Ашарсың да туярсың,*
*Баш очыңа куярсың.*



## СӨЙЛӘМ ТАКМАКЛАРЫ

### КӘҖӘ ТУРЫНДА

*Кәҗә кергән бакчага,*
*Кәбестәне ашарга,*
*Таяк тотып чыксалар,*
*Хәзер тора качарга.*
*Кәҗә кергән бакчага,*
*Ачы суган ашарга,*
*Ачы суган кикертә,*
*Түтәл аша сикертә.*
*Кәҗә, шилма, мәкәрҗә,*
*Йөзе кара мал икән.*
*Харап иткән бакчаны,*
*Түтәлләрне көл иткән.*

* * *

*Кәҗә кергән бакчага,*
*Кәбестәне ашарга.*
*Таяк тотып чыксалар,*
*Хәзер тора качарга.*
*Таяк белән чыбыкка*
*Кәҗә малы бирешми.*
*Дөнья күргән кәҗәгә*
*Аннан курку килешми.*
*Ул алай да шикләнә,*
*Әрле-бирле чапкалый.*
*Кеше куып җиткәнче,*
*Һаман өзеп капкалый.*

# Талкыш кәләвә:
## Борһан бабай бүләге

**Татар аш-су культурасы, аның формалашуы һәм үсеше төрле тарихи чорның икътисади, сәяси, социаль факторларына, халыкның яшәү рәвешенә дә бәйле.**

**Урта Идел буе һәм Урал буе татарларының этногенезы үсешенә төрки халыклар белән бергә фин-угыр кабиләләре үз өлешен кертә. Бу бәйләнешлардан милли аш-су да читтә калмый, әлбәттә. «Талкыш кәләвә» дип аталган милли ризык яңарышның матур бер үрнәге булып тора.**

**Бу десертның барлыкка килүе XIX гасыр азагына барып тоташа. Казан губернасына аның рецептын төрек әсирлегендә булган Борһан бабай алып кайта. Мөселман егетенә әсирлектә кондитер ярдәмчесе булып эшләргә туры килә. Аның төрек хуҗасы яхшы кеше булып чыга – соңрак билет алып Борһан Сафиуллинны туган иленә озата. Бу хакта журналистларга аның оныгы Нияз Сафиуллин сөйли.**

*«Татар гаиләсенең чәй табынында бал торган. Татар хуҗабикәсе чәй табынына итле һәм баллы бәлешләр, коймак, кабартма, бавырсак, чәк-чәк куйган. XIX гасыр азагы XX гасыр башында бал урынына шикәр куя башлаганнар».*



Казанга кайткач Борһан бабай төрек кухнясының берничә ризыгы рецептын кулланып, бал, шикәр комы, май, он һәм су кушып, яңа ризык уйлап таба. Ул аны «талкыш кәләвә» дип атый. Баллы ризыкны Казан татарлары бик тиз үз итә, заказ да бирә башлыйлар. Сафиуллиннар гаиләсенең иртә таңнан пешергән талкыш кәләвәсе, төш җиткәндә сатылып та бетә. XX гасыр урталарында, илнең икътисади вазгыяте авырайгач, кешедә баллы-татлы ризык кайгысы калмый, талкыш кәләвәне хәлле татарлар гына ашый, заказ биргәндә аның ингредиентларын үзләре китерә башлый. Соңрак талкыш кәләвә бөтенләй онытыла.

Илленче елларда легендар пешекче, татар аш-суы буенча беренче классик хезмәт саналган «Татар халык ашлары» китабын төзүче автор Юныс Әхмәтҗанов, Борһан Сафиуллинның кызы Фахирә Сәйфуллина белән аралашып, талкыш кәләвә әзерләүнең уникаль рецептын язып ала.



Туксанынчы еллар башында Борһан Сафиуллинның дәвамчылары талкыш кәләвә җитештерүне оештырып җибәрә. Хәзер бу татлы ризык «Бәхетле» супермаркетында да, сувенир лавкаларында да сатыла.

Талкыш кәләвә әзерләү шактый катлаулы хезмәт. Шуңа аны ясаучы осталар да күп түгел. Сезне шундыйларның берсе – Сәлимә Кыям кызы Нәҗметдинова белән таныштырабыз. Сәлимә ханым Әтнә районының Каенсар авылында яши. Ул 1966 елда Арча районының Иске Кырлай авылында туган. Талкыш кәләвә ясау осталыгына әбисеннән өйрәнгән. Аны ясау серләрен безгә ул ачты. Талкыш кәләвә ясау һәр хуҗабикәнең хәленнән килмәскә дә мөмкин. Әмма ясап та, татып та карарга кирәк. Мондый татлы ризыктан баш тарту мөмкин түгел.

Сәлимә ханым талкыш кәләвәне бик яратып ясый, заказлар да ала. Аның янына торт, чәк-чәк, бавырсак, кош теле һәм урама әзерләвен сорап киләләр. Аның баллы ризыклары үз районында гына түгел, тирә-күрше районнарда да бик популяр.

Әлмәт, Әтнә, Баулы районнарында яшәүче талкыш кәләвә ясаучы осталар үзләренең хосусый предприятиеләрен ачалар. Татарның бу милли ризыгын Оренбургта, Уфада да ясыйлар. Әлеге ризык фестивальләрдә татар милли ризыгы, татар гастрономия культурасы буларак тәкъдим ителә.

**Рабига МӘҺДИЕВА,**
**Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге методисты**

**Гөлия ШӘЙХИЕВА,**
**Әтнә районы, Әйшияз авыл клубы мөдире**

**Кирәкле ингредиентлар:**


**50 грамм бал,**
**146 грамм шикәр комы,**
**50 мл су,**
**30 грамм эретелгән ак май,**
**51 грамм он.**





1

Иң элек май белән оннан әлбә ясыйбыз. Акмайны эретәбез.





2

Эретелгән акмайга аз-азлап кына он салып, болгата-болгата пешерәбез. Бераз вакыттан масса сыекланып, өстенә тигез булып май чыккач һәм чикләвек төсенә кергәч, әлбә әзер дигән сүз.





3

Икенче савытта шикәр комына су, бал кушып көрән төскә кергәнче сироп кайнатабыз (ул карамельга әверелә).




4

Әзер сиропны майланган салкын табага бушатып, суытырга куябыз. Шул ук вакытта төрле яктан массаны кашык белән төрткәләп торабыз – моны катып киткәнче эшләргә кирәк. Масса куергач һәм кулга тотарлык булып суынгач, аны урталай бөкли-бөкли озак итеп, масса ялтырап торган ак төскә кергәнче, сузарга кирәк. Моны бал кайнар һәм сузылучан чагында өзмичә тиз-тиз эшлиләр.



5

Әлбәне куна тактасына салып, өстенә баллы массаны куеп баш-башыннан сузабыз. Майлы әлбә балга бик тиз сеңеп бетә һәм нечкә генә ак җепселләр булып сузыла башлый.




6

Талкыш кәләвәнең тиз сынучан җепселләрен куна тактасына җәеп салабыз, бармак белән баскалап формага тутырабыз. Аннары форманы әйләндереп каплап, талкыш кәләвәне чыгарабыз. Формасыннан алган талкыш кәләвәләрне салкын урынга куябыз.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**

Зөлфия Габделхакова фоторәсемнәре

# Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы «ферзь»нең дөрес йөреш тәртибен кулланып, шагыйрә Илсөяр Иксанованың «Көзге сагыш» шигыреннән дүртьюллык укыгыз.


| | Т | т | ы | м | а | - | я | г |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ы | - | н | р | н | к | ф | з | е |
| п | г | у | н | а | р | ө | я | г |
| ы | а | а | р | а | К | ф | а | ы |
| н | р | ф | к | а. | р | с | ш, | ы |
| д | Я | с | в | а | м | М | н | м |
| а | а | я | к | е | и | а | с | л |
| г | ш | - | н | н | ж | а | ш | а |
| ы | м | и | е | м | г | ы | н | а. |

**ШАХВОРД ҖАВАБЫ – САННАРДА**

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Дүртьюллык 80 хәрефтән тора.

| | 1 | 5 | 6 | 14 | 15 | 27 | 28 | 44 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 4 | 7 | 13 | 16 | 26 | 29 | 43 | 45 |
| 3 | 8 | 12 | 17 | 25 | 30 | 42 | 46 | 59 |
| 9 | 11 | 18 | 24 | 31 | 41 | 47 | 58 | 60 |
| 10 | 19 | 23 | 32 | 40 | 48 | 57 | 61 | 70 |
| 20 | 22 | 33 | 39 | 49 | 56 | 62 | 69 | 71 |
| 21 | 34 | 38 | 50 | 55 | 63 | 68 | 72 | 77 |
| 35 | 37 | 51 | 54 | 64 | 67 | 73 | 76 | 78 |
| 36 | 52 | 53 | 65 | 66 | 74 | 75 | 79 | 80 |

Ферзьнең йөреш тәртибе



**Шахворднын җавабы**

Тып-тын гына урманнарда
Яфрак-яфрак сагыш ява.
Көзге яфрак – минем сагыш,
Минем җаным сагышлана.

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле даталар
2022

## ОКТЯБРЬ

**6 октябрь**

Театр тәнкыйтьчесе, сәнгать фәннәре докторы, профессор, ТРның Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Гали (Мөхәммәтгали) Гыйльмегали улы Арслановка 75 яшь (1947)

**11 октябрь**

Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Габделфәт Габдрахман улы Сафинга 60 яшь (1962)

**15 октябрь**

Татарстан Республикасының дәүләт эшлеклесе, философия фәннәре кандидаты, РФ Хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Рәхимьян кызы Вәлиевага 70 яшь (1952)

**18 октябрь**

Актёр, ТАССРның халык артисты Әнвәр Габдрахман улы Гобәйдуллинның тууына 100 ел (1922-2012)

**18 октябрь**

Драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Габдулла улы Сафиуллинга 75 яшь (1947)

**22 октябрь**

Шагыйрә Лилия Рәфхәт кызы Фәттаховага 50 яшь (1972)

**24 октябрь**

Гамәли бизәлеш рәссамы Елена Николаевна Шмелёвага 70 яшь (1952)

## НОЯБРЬ

**5 ноябрь**

Актёр, режиссёр, ТАССРның атказанган артисты Бари Шиһабетдин улы Тархановның (Гаффаров) тууына 130 ел (1892-1933)

**20 ноябрь**

Җырчы, ТАССРның, Каракалпак АССРның һәм РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Ислам улы Ибраһимовка 75 яшь (1947-2022)

**21 ноябрь**

«Созвездие-Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм итү буенча республика үзәге» ДБУ директоры, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, мәдәният өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе лауреаты Дмитрий Александрович Тумановка 60 яшь (1962)

**22 ноябрь**

Җырчы, педагог, профессор, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллинаның тууына 100 ел (1922-1994)

**25 ноябрь**

Скульптор, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Асия Миңневәли кызы Миңнуллинага 70 яшь (1952)

**27 ноябрь**

Актёр, режиссёр, педагог, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, РФ Хөкүмәтенең Ф. Волков исемендәге премияләре лауреаты, В.И. Качалов исемендәге Казан Зур рус драма театрының сәнгать җитәкчесе, директоры Александр Яковлевич Славутскийга 75 яшь (1947)

**30 ноябрь**

Казан дәүләт яшь тамашачылар театры ачылуга 90 ел (1932)

## ДЕКАБРЬ

**3 декабрь**

Скульптор, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Нәүфәл Исмәгыйль улы Адыловның тууына 90 ел (1932-2004)


**11 декабрь**

Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Фәридә Шаһимәрдан кызы Хәсьяновага 70 яшь (1952)

**24 декабрь**

Актриса, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Светлана Геннадьевна Славутская (Романова) 70 яшь (1952)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**









**Кадерле укучыларыбыз!**
2023 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!